# АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮЧӘЛЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕН ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

## 1 БҮЛЕК. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Үчәлле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) куркынычсыз, уңайлы һәм күркәм авыл тирәлеген булдыру өчен төп параметрларны һәм төзекләндерү элементларының зарури минималь кушылмасын билгели, тышкы төзекләндерү өлкәсендә бердәм һәм үтәү өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне һәм таләпләрне билгели, физик затлар өчен дә, юридик затлар өчен дә авыл җирлеге территорияләрен карап тоту тәртибен ачыклый.

1.2. Кагыйдәләр территорияләрне төзекләндерү, төзекләндерелгән территорияләрне эксплуатацияләү буенча чараларны проектлаганда, аларга контрольлекне гамәлгә ашырганда кулланылырга мөмкин.

1.3. Кагыйдәләр Үчәлле авыл җирлеге территориясендә торучы һәм (яки) үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашыручы органнар, оешмалар, берләшмәләр һәм үзләренең оешу-хокукый формасы һәм кайсы ведомствоныкы булуына бәйсез рәвештә бүтән юридик затлар, шулай ук гражданнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

1.4. Әлеге Кагыйдәләрдә түбәндәге норматив документларга сылтамалар кулланылды:

СП 51.13330.2011 «СНиП 23-03-2003. Тавыштан яклау».

СП 17.13330.2011 «СНиП II-26-76. Түбәләр. Проектлау нормасы».

СП 20.13330.2011 «СНиП 2.01.07-85* Басымнар һәм йогынтылар».

СНиП 2.01.15-90 «Территорияләрне, биналарны һәм корылмаларны куркынычлы геологик процесслардан инженер саклау».

СП 31.13330.2010 «СНиП 2.04.02-84*. Су белән тәэмин итү. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар.

СП 32.13330.2010 «СНиП 2.04.03-85. Канализация. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар»

СП 34.13330.2010 «СНиП 2.05.02-85*. Автомобиль юллары»

СП 42.13330.20011 «СНиП 2.07.01-89*. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзеп тутыру».

СанПиН 42-128-4690-88 «Торак урыннар территорияләрен карап тотуның санитар нормалары».

СНиП 21-01-97* «Биналарның һәм корылмаларның янгын куркынычсызлыгы».

СП 52.13330.2011 «СНиП 23-05-95*. Табигый һәм ясалма яктырту».

СН 541-52 «Шәһәрләрне, бистәләрне һәм авыл торак пунктларын тышкы яктан яктыртуны проектлау буенча күрсәтмә».

СП 59.13330.2010 «СНиП 35-01-2001. Биналарның һәм корылмаларның аз хәрәкәтләнүче халык төркемнәре өчен мөмкинлекле булуы».

СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 «Предприятиеләрнең, корылмаларның һәм бүтән объектларның санитар-саклык зоналары һәм санитар классификациясе».

СанПиН 2.1.5.980-00 «Өслек суларын саклауга карата гигиена таләпләре».

ГОСТ Р 52289-2004 «Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары».

ГОСТ 26804-86 «Барьер тибындагы металл юл коймалары».

ГОСТ Р 52290-2004 «Юл билгеләре. Гомуми техник таләпләр».

ГОСТ Р 51256-99 «Юл тамгасы».

ГОСТ Р 52044-2003 «Тышкы реклама чараларына гомуми техник таләпләр. Урнаштыру кагыйдәләре».

1.5. Әлеге Кагыйдәләрдә тиешле билгеләмәләре белән түбәндәге терминнар кулланыла:

**Территорияне төзекләндерү** – инженер әзерлек һәм куркынычсызлык тәэмин итү, яшелләндерү, түшәмәләр урнаштыру, яктырту, кече архитектура формаларын һәм монумент сәнгате объектларын урнаштыру буенча чаралар комплексы.

**Территорияне төзекләндерү элементлары** – төзекләндерүнең җыелма өлеше буларак кулланыла торган декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, үсемлек компонентлары, җиһазлауның һәм бизәүнең төрле төрләре, кече архитектура формалары, капиталь һәм стационар булмаган корылмалар, тышкы реклама һәм мәгълүмат.

**Төзекләндерү элементларын нормага салу комплексы** – авыл җирлеге территориясендә куркынычсыз, уңайлы һәм күркәм тирәлек булдыру өчен кирәкле төзекләндерү элементларының минималь кушылмасы.

Төзекләндерү элементларын нормага салу комплексы җирле нормалар һәм Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре составында билгеләнә.

**Территорияне төзекләндерү объектлары** – төзекләндерү эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган авыл җирлеге территорияләре: мәйданчыклар, ишегаллары, кварталлар, вазыйфаи-планлаштыру берәмлекләре, шулай ук бердәм шәһәр төзү регламентациясе (саклык зоналары) яки визуаль-тирәлекле кабул итү (төзелмәләре булган мәйдан, чиктәш территориясе һәм төзеләмәләре булган урам) принцибы буенча аерып чыгарыла торган территорияләр, авыл җирлегенең башка территорияләре.

**Территорияне төзекләндерүне нормага салу объектлары** – Территорияне төзекләндерү кагыйдәләрендә алар өчен түбәндәгеләр билгеләнә торган авыл җирлеге территорияләре: төзекләндерү элементларын нормага салу комплексы, аларны әлеге территориядә урнаштыру кагыйдәләре. Мондый территорияләр булып түбәндәгеләр торырга мөмкин: төрле вазыйфаи билгеләнештәге мәйданчыклар, җәяүлеләр өчен коммуникацияләр, юллар, иҗтимагый тирәлекләр, иҗтимагый, торак төзелеше урыннары һәм зоналары, җитештерү төзелешенең санитар-саклык зоналары, рекреация объектлары, торак пунктының урам-юл челтәре, инженер коммуникацияләрнең техник (сак-эксплуатация) зоналары.

**Территорияләрне җыештыру** – җитештерү һәм куллану калдыкларын, башка чүпне җыюга, калдыкларның махсус билгеләнгән урыннарына чыгаруга бәйле эшчәнлек төре, шулай ук халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлеген һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән бүтән чаралар.

**Ташландык транспорт чарасы** – милекчесе тарафыннан алты һәм аннан күбрәк айлык срокка башка затларның аннан ирекле файдалана алуын чикләми торган торышта (ишекләре, кузовның тәрәзә элементлары, кузовның башка төрле элементлары булмавы, ишекләренең бикләнмәве, ишекләрен бикләү мөмкинлеге булмавы сәбәпле һ.б.) калдырылган, шулай ук билгеләнеше буенча файдалану мөмкинлеге булмау билгеләренә ия булган (тәгәрмәчләре тишелгән, тәгәрмәчләре яки башка төрле конструктив детальләре юк һәм башкалар) һәм шул ук вакытта уртак файдалана торган (йорт яны территорияләрендә), транспорт чараларын саклау өчен билгеләнмәгән (транспорт чараларын урнаштыру өчен махсус билгеләнгән урыннардан читтә) урыннарда торган яки озак вакыт дәвамында (алты ай һәм аннан да күбрәк) транспорт чараларын урнаштыру өчен махсус билгеләнгән урыннарда (парковкаларда, парковкага куя торган урыннарда, түләүле автотукталышларда, гаражлардан яки техника саклау өчен билгеләнгән башка төрле биналардан, урыннардан тыш) торучы һәм транспорт белән үтәргә, җәяүлеләргә йөрергә, территорияне җыештырырга, ашыгыч хезмәт күрсәтүче автомашиналарның, башка төрле махсус транспортларның, чүп җыючы машиналарның подъездларга, чүп контейнерларына үтеп керүенә комачаулый торган һәм (яки) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен бозып урнаштырылган транспорт чарасы. Ташландык транспорт чарасы, транспорт белән үтәргә, җәяүлеләргә йөрергә, территорияне җыештырырга, ашыгыч хезмәт күрсәтүче автомашиналарның, башка төрле махсус транспортларның, чүп җыючы машиналарның подъездларга, чүп контейнерларына үтеп керүдә булган каршылыкларны бетерү, шулай ук потенциаль террорчылык куркынычын юкка чыгару максатларында билгеләнгән тәртиптә эвакуацияләнергә тиеш.

**Транспорт чараларын урнаштыру өчен махсус билгеләнгән урыннар** – законнарга туры китереп оештырылган автомобиль тукталышы урыннары, гаражлар, төзәтә торган остаханәләр һәм техника саклау (техникага хезмәт күрсәтү) өчен билгеләнгән башка төрле биналар, урыннар; Министрлар Советы – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юл йөрү кагыйдәләре турында» 1993 елның 23 октябрендәге 1090 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Юл йөрү кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән парковкалар (парковкага кую урыннары).

**Йорт яны территориясе** – торак күпфатирлы бинага чиктәш булып торучы, яшелләндерү элементларын, керә торган урыннарга җәяүләп керә торган, йортка транспорт белән килә торган юлларны, әлеге йортта яшәүчеләр өчен мәйданчыкларны (балалар өчен, спорт, ял итү, контейнерлар, этләрне йөртеп керү өчен) һәм йортка хезмәт күрсәтү, аны эксплуатацияләү һәм

төзекләндерү өчен билгеләнгән бүтән объектларны үз эченә алган җир кишәрлеге.

**Йорт хайваны** – физик яки юридик затта асрауда торучы хайван.

**Йорт хайваны асрау** – йорт хайванының хуҗасы тарафыннан хайванның гомерен һәм сәламәтлеген саклау, йорт хайваныннан сәламәт токым алу, шулай ук җәмәгатьчелек тәртибен һәм кешеләрнең һәм хайваннарның иминлеген тәэмин итү өчен күрелә торган чаралар.

1.6. Үчәлле авыл җирлеге территориясендә әлеге Кагыйдәләрнең таләпләре үтәлүен тикшерүдә тотуны авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе яки белгеч гамәлгә ашыра.

## 2 БҮЛЕК.
## ТЕРРИТОРИЯНЕ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ЭЛЕМЕНТЛАРЫ

2.1. Территорияне инженер әзерләү һәм саклау элементлары

2.1.1. Территорияне инженер әзерләү һәм саклау элементлары территориядән файдалануның куркынычсыз һәм уңайлы булуын, яңа төзелешкә яки реконструкциягә бәйле рәвештә аны табигый һәм техноген йогынтының тискәре күренешләреннән саклауны тәэмин итә. Территорияне инженер әзерләү һәм яклау элементларын проектлау рельефны һәм җир өслеге сулары агынтысын оештыру буенча чаралар составында башкарыла.

2.1.2. Төзекләндерүне проектлаганда рельеф оештыру бурычларын территориянең вазыйфаи билгеләнешеннән һәм аны үзгәртеп кору һәм реконструкцияләү максатларыннан чыгып билгеләргә кирәк. Реконструкцияләнә торган территория рельефын оештыруны, кагыйдә буларак, рефльефны, туфрак капламын, булган яшел утыртмаларны, тиешле җир өслеге су бүлгече шартларын максималь саклауга, чыгарыла торган грунтларны төзелеш мәйданчыгында файдалануга юнәлтергә кирәк.

2.1.3. Рефльефны оештырганда туфракның 150-200 мм калынлыгындагы уңдырышлы өслеген салдыруны һәм аны вакытлыча саклау урынын җиһазландыруны, ә анда теләсә нинди төрдәге пычратуның нормадан артык өлеше булмавы расланса, пычранудан яклау чараларын күздә тотарга кирәк. Грунтны өстәп салганда территориядә фәкать минерал грунтларны һәм туфракның өске уңдырышлы катламнарын гына кулланырга рөхсәт ителә.

2.1.4. Рельефны террасалаганда терәүгә куелган диварчыклар һәм авыш янтыклар проектларга. Авыш янтык почмакларының максималь рөхсәт ителә торган зурлыклары грунтларның төренә, аларның консистенциясенә, тыгызлыгына һәм төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә авыш янтык биеклегенә карап билгеләнә.

2.1.5. Авыш янтыкларны ныгытырга. Ныгыту материалын һәм технологиясен сайлау авыш янтык урнашкан урынга, сөзәк урынга механик басымнарның күзалланган дәрәҗәсенә, сөзәклекнең һәм формалаштырыла торган тирәлекнең текәлегенә бәйле.

2.1.6. Терәүгә куела торган диварчыкларны берләштерелә торган

террасалар биеклегенең аермасын исәпкә алып проектларга кирәк. 0,4 м азрак төшкән рельефны борт ташы яки табигый таш салып ясарга киңәш ителә. Рельеф 0.4 м артыграк төшкәндә, терәүгә куела торган диварчыклар терәүле диварчыкларның гравитацияле (авыр итеп корылган монолитлы) яки субайлы (юка анкерлы, субайлы түшәлмәләр) төрләре белән өске террасаның тотрыклылыгын тәэмин итеп, инженер корылма буларак проектлана.

2.1.7. Аларга транспорт коммуникацияләрен урнаштырганда терәүле диварчыкларны һәм авыш янтыкларның өске кырый сызыкларын ГОСТ Р 52289, ГОСТ 26804 туры китереп киртәләүне күздә тотарга кирәк. Шулай ук әлеге корылмалар тирәли урнаштырыла торган җәяүле юлларын да, терәүле диварчык 1,0 м биегрәк, ә авыш янтык 2 м биегрәк булганда, киртәләп алуны күздә тотарга кирәк. Коймаларның биеклеге – кимендә 0,9 м.

2.1.8. Магистраль юллар буйлап урнаша торган ясалма рельеф элементлары (терәк диварлар, җир өемнәре, уемнар) тавыштан саклаучы экраннар рәвешендә файдаланылырга мөмкин.

2.1.9. Җир өслеге сулары агынтысын проектлаганда СНиП 2.04.03 таянып эш итәргә кирәк. Агынты оештырганда рельефны оештыру һәм су агызу җайланмаларының ачык яки ябык системасын: су агызу трубаларын (су агып төшә торган җайланмаларны), улакларны, кюветларны, нык авыш улакларны, яңгыр суларын кабул итүче коеларны урнаштыру мәсьәләләренең комплекслы хәл ителүен тәэмин итәргә кирәк. Җир өслегендәге су бүлгечне проектлау җир эшләренең минималь күләмендә һәм суның тиз, туфрак эрозиясе мөмкинлеген калдырмаслык итеп агуын күздә тотып гамәлгә ашырылырга тиеш.

2.1.10. Ачык су бүлү җайланмаларын куллану парклар һәм урман парклары территорияләре чикләрендә рөхсәт ителә. Ачык улакларны (канауларны, кюветларны) төбе яки барлык периметры буенча ныгытырга (кәс, таш, монолит бетон, җыелма тимер-бетон, керамика һ.б.), кюветларның авыш янтыклы почмагын грунт төрләренә карап кулланырга кирәк.

2.1.11. Минималь һәм максималь авышлыкларны суның юдырмый торган тизлекләрен исәпкә алып билгеләргә кирәк, мондый тизлекләр су бүлү элементларының каплау төренә карап билгеләнә. Яңгыр суларының агу тизлеге максималь мөмкин булганнан югарырак булган рефльеф урыннарында суны тиз агыза торган җайланмалар (басмалы су төшергечләр) урнаштырылуын тәэмин итәргә кирәк.

2.1.12. Рекреация объектлары территорияләрендә су бүлү улаклары җәяүле коммуникацияләре түшәмәсенең газон белән тоташуын тәэмин итә ала, аларны түшәү элементларыннан (яссы йомры таш, шакмаклап ватылган яки киселгән таш, таш плитә һ.б.) ясарга киңәш ителә, ялганыш урыннарын югары сыйфатлы балчык измәсе белән сылап куярга киңәш ителә.

2.2. Яшелләндерү.

2.2.1. Яшелләндерү – территорияне яшелләндерү һәм ландшафтын оештыру элементы, авыл җирлеге тирәлеген үсемлек компонентларыннан актив файдаланып формалаштыруны, шулай ук авыл җирлеге территориясендә элегрәк ясалган яки баштан ук булган табигый тирәлекне саклап тотуны тәэмин

итә.

2.2.2. Утыртмаларның һәм яшелләндерүнең төп типлары булып түбәндәгеләр тора: агач биләмәләре, агач төркемнәре, агачтан тасма суалчаннар, тере читәннәр, ян утыртмалар, кечкенә урманнар, ике яклап утыртылган агачлар, газоннар, чәчәклекләр, утыртмаларның төрле төрләре (аллея, рәт, бәйләм итеп һ.б.). Утыртмаларның тибын сайлауга карап, утыртмаларның күләм-структура төзелеше билгеләнә һәм яшелләндерелгән территорияләрнең үзара һәм торак пунктындагы төзелмәләр белән визуаль-композицион һәм вазыйфаи бәйләнеше тәэмин ителә.

2.2.3. Үчәлле авыл җирлеге территориясендә яшелләндерүнең ике төре кулланылырга мөмкин: стационар – үсемлекләрне грунтка утырту һәм мобиль – үсемлекләрне махсус күчмә савытларга (контейнерларга, чүлмәкләргә һ.б. утырту). Стационар һәм мобиль яшелләндерү гадәттә табигый һәм ясалма рельеф элементларында архитектура-ландшафт объектларын (газоннар, бакчалар, чәчәклекләр, куаклы һәм агачлы мәйданчыклар һ.б.) булдыру өчен, биналарның һәм корылмаларның түбәләрендә (түбә яшелләндерү), фасадларында (вертикаль яшелләндерү) кулланыла.

2.2.4. Яшелләндерүне проектлаганда: агач һәм куаклык утыртмаларының инженер челтәрләренә, биналарга һәм корылмаларга кадәрге минималь аралыгын, утыртмаларны утырту өчен кантарларның, чокырларның һәм траншеяләрнең зурлыкларын (әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтаның 2 нче таблицасы) исәпкә алырга кирәк. Торак пунктының төрле территорияләрендә утыртмаларның максималь күләмен (әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтаның 3 нче таблицасы), төрле вазыйфаи билгеләнештәге урыннарда яшелләндерелә торган территорияләрнең чамаланган процентын һәм утырту материалын сортларга аеру өчен таләпләрне (әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтаның 4-9 таблицалары) сакларга киңәш ителә.

2.2.6. Җылылык трассалары эшләгән зоналарда агачлар утыртканда җылылык трассасы күчәреннән һәр яклап туфрак интенсив җылынганда – 2 м кадәр, уртача җылынганда – 2-6 м, аз җылынганда – 6-10 м аралыгында туфракның җылыну факторын исәпкә алу зарур. Җылылык трассалары янында түбәндәгеләрне урнаштырырга киңәш ителми: юкә, өрәңге, сирин, зелпе – 2 м якынрак, дүләнә, кизил куагы, кәсләр, карагай, каен – 3-4 м якынрак.

2.2.7. Тискәре техноген һәм климат факторлары торак пунктындагы төрле территорияләргә йогынты ясаганда, яклагыч утыртмалар формалаштырырга киңәш ителә; берничә фактор йогынтысы булганда ешлыгы һәм (яки) территориянең вазыйфаи билгеләнеше өчен аеруча әһәмиятлелеге буенча өстен торучысын сайларга киңәш ителә.

2.2.8.1. Җилдән саклау өчен чаршавының вертикаль йомыклыгы 60-70%лы челтәрле конструкцияле яшел утыртмаларны куллану киңәш ителә.

2.2.8.2. Тавыштан саклаучы утыртмаларны бер рәтле яки күп рәтле кимендә 7 м рәт утыртмалары рәвешендә, рәттә өлкән агачларның кәүсәләре арасындагы аралыкны 8-10 м зурлыгында (киң ябалдашлы булганда), 5-6 м (уртача ябалдашлы), 3-4 м (тар ябалдашлы) тәэмин итеп проектларга, тирәлекне

куак рәтләре белән тутырырга. Тавыш кимүнең кötелгән дәрәҗәсе әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтаның 7 таблицасында күрсәтелде.

2.2.8.3. Һаваның пычрану дәрәҗәсе югары торган шартларда күп рәтле агач-куак утыртмалары формалаштырырга: җилләтү режимы яхшы булганда – ябык типлы (ябалдашлары йомыла), җилләтү режимы начар булганда – ачык, иләкләүче тибында (ябалдашлары йомылмый).

2.3. Өслекләрне тоташтыру.

2.3.1. Өслекләрне тоташтыру элементларына борт ташларының төрле төрләрен, пандусларны, басмаларны, баскычларны кертәләр.

**Борт ташлары**

2.3.2. Тротуар белән юл тоташкан өлештә бортлы юл ташларын куярга киңәш ителә. Борт ташларын юл өслеге дәрәҗәсеннән кимендә 150 мм норматив арттырып куярга киңәш ителә, ул түшәмә өслекләрен төзәткән очракта да сакланырга тиеш. Газон белән юл түшәмәсе тоташкан урыннарда газонга автотранспорт үтеп керүен булдырмас өчен үзәк урамнарда, шулай ук эре хезмәт күрсәтү объектларындагы автотукталыш мәйданчыкларында биегәйтелгән борт ташын кулланырга киңәш ителә.

2.3.3. Җәяүле коммуникацияләре түшәмәсе газон белән тоташканда кимендә 0,5 м аралыгында газон өстеннән кимендә 50 мм биеклек бирә торган бакча бортын урнаштырырга мөмкин, ул газонны саклый һәм түшәмәгә пычрак һәм үсемлек чүбе эләгүен булдырмый, аның хезмәт итү срогын озынайта. Җәяүлеләр зоналары территориясендә төрле типтагы түшәмәләргә тоташкан урыннарны ясау өчен табигый материаллардан (кирпеч, агач, йомры ташлар, керамик борт һ.б.) файдаланырга мөмкин.

**Басмалар, баскычлар, пандуслар**

2.3.4. Җәяүле коммуникацияләренең авышлыгы 60% артыграк булганда баскычлар урнаштыруны күздә тотарга кирәк. Сәламәтлек саклау учреждениеләре һәм массакүләм килә торган башка объектлар урнашкан урыннарда төп җәяүле коммуникацияләрендә авышлыкларның дәрәҗәсе 50% артыграк булганда зарури тәртиптә пандуслар белән тәэмин итеп, басмаларны һәм баскычларны күздә тотарга кирәк. Төп җәяүле коммуникацияләре юллар белән кисешкәндә яки башка, бинада проектлау өчен сөйләшенгән очракларда тротуар түшәмәсеннән юл түшәмәсенә чыгуны тәэмин итү өчен бордюр пандусын күздә тотарга кирәк.

2.3.5. Рельеф сикертмәләрендә ачык баскычларны проектлаганда басмаларның биеклеге – кимендә 120 мм, киңлеге – кимендә 400 мм һәм югары торучы басма ягына таба авышлыгы – 10-20%. Һәр 10-12 басмадан соң кимендә 1,5 м озынлыгында мәйданчыклар урнаштырырга. Төшкәндә һәм менгәндә баскычларның беренче басма кырыйларын ачык контраст төсендәге полосалар белән аерып күрсәтергә. Бер марш чикләрендәге тышкы баскычларның барлык басмаларын да басманың киңлеге һәм күтәрелеш биеклеге буенча бертөрле итеп урнаштырырга кирәк. Инде бар булган торак пункты территорияләрен реконструкцияләү шартларында баскычлар проектлаганда, басмаларның биеклеге 150 мм кадәр арттырылырга, ә басмаларның киңлеге һәм

мәйданчыкның озынлыгы тиешенчә 300 мм кадәр һәм 1,0 м кадәр киметелергә мөмкин.

2.3.6. Пандус шумый торган материалдан кытыршы текстуралы өслек белән, яссы чокырлар калдырмыйча ясала. Читләтеп тора торган пандус конструкцияләре булмаганда биеклеге кимендә 75 мм һәм тоткычлары булган киртәләп торучы бортны күздә тотарга кирәк. Күтәрелеш биеклегеннән пандус авышлыгының бәйләнешен әлеге Кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасындагы 12 нче таблицасына карап кулланырга. Бордюр пандусы авышлыгын иң күбе 1:12 исәбеннән кулланырга.

2.3.7. Пандус борылганда яки аның озынлыгы 9 м артыграк булганда, һәр 9 м артмаган ешлыкта 1,5x1,5 м зурлыгындагы яссы мәйданчыклар ясауны күздә тотарга кирәк. Төшү өлеше тәмамланган яссы мәйданчыкларда дренаж җайланмаларын проектларга кирәк. Пандус башында һәм ахырында юлның яссы өлешләрен әйләнә-тирәлек өслегеннән аерылып тора торган текстура һәм төс белән эшләргә кирәк.

2.3.8. Баскычның яки пандусның ике ягыннан да 800-920 мм биеклегендә түгәрәкләр яки дүртпочмаклап киселгән, кул белән тоту өчен уңайлы һәм стенадан 40 мм ераклыкта торучы тоткычлар карарга кирәк. Баскычларның киңлеге 2,5 м һәм аннан күбрәк булганда, аерып торучы тоткычларны күздә тотарга. Тоткычларның озынлыгын пандус яки баскыч озынлыгыннан һәр яктан да кимендә 0,3 м зуррак итеп, тоткычларның башларын йомры һәм шома итеп урнаштырырга кирәк. Проектлаганда кулның металл белән тоташуын чикли торган тоткыч конструкцияләрен карарга кирәк.

2.3.9. Җирнең (шул исәптән үлән түшәлгән) сөзәк урыннары баскычларга, пандусларга, терәүле диварларга, башка техник инженер корылмаларына тоташкан зоналарда әлеге Кагыйдәләрнең 2.1.5 пунктына ярашлы чаралар башкарыла.

2.4. Коймалар.

2.4.1. Төзекләндерү максатларында Үчәлле авыл җирлеге территориясендә коймаларның төрле төрләрен күздә тотарга киңәш ителә, алар түбәндәгечә аерыла: билгеләнеше буенча (бизәү, саклау өчен, икесенең бергә кушылуы), биеклеге буенча (тәбәнәк – 0,3-1,0 м, уртача – 1,1-1,7 м, биек – 1,8-3,0 м), материал төре буенча (металл, тимер-бетон һ.б.), карау буенча үтеп керүчәнлек дәрәҗәсе буенча (үтәкүренмәле, каты), стационар дәрәҗәсе буенча (даими, вакытлыча, күчереп йөртелә торган).

2.4.2. Коймаларны аларның урнашкан урынына һәм ГОСТлар буенча билгеләнешенә, сертификатланган эшләнмәләрнең каталогларына, хосусый проектлау проектларына туры китереп проектларга кирәк.

2.4.2.1. Тарихи-мәдәни мирас һәйкәлләре территорияләрен әлеге территорияләр өчен билгеләнгән регламентларга ярашлы рәвештә коймаларга киңәш ителә.

2.4.2.2. Иҗтимагый, торак, рекреация билгеләнешендәге территорияләрдә каты һәм тимер-бетон коймалар проектлау рөхсәт ителми. Декоратив металл коймалар кулланырга киңәш ителә.

2.4.3. Газоннар подъездларга, автотранспорт тукталышы урыннарына тоташкан җирләрдә, автомобильләрнең газонга үтү һәм газон аша сукмаклар тапталу мөмкинлеге булган урыннарда кимендә 0,5 м биеклегендә яклаучы металл коймалар урнаштыруны күздә тоту киңәш ителә. Коймаларны газон территориясендә тоташкан урын чигеннән 0,2-0,3 м тирәсе аралык калдырып урнаштырырга киңәш ителә.

2.4.4. Җир асты корылмалары белән кисешкән урыннарда коймаларның уртача һәм биек төрләрен проектлаганда төзәтү яки төзү эшләрен башкару мөмкинлеген бирә торган койма конструкцияләрен күздә тотарга кирәк.

2.4.5. Җәяүлеләр интенсив йөргән зоналарда яки төзү һәм үзгәртеп кору эшләрен башкару зоналарында агачлар үскәндә, яклауның башка төрләре булмаганда агачның яшенә, токымына һәм башка төрле сыйфатламаларына карап, биеклеге 0,9 м һәм аннан биегрәк, диаметры 0,8 м һәм аннан артыграк булган кәүсә тирәли яклагыч коймалар урнаштыруны күздә тотарга кирәк.

2.5. Кече архитектура формалары.

2.5.1. Кече архитектура формаларына (КАФ) түбәндәгеләр карый: Үчәлле авыл җирлеге территориясендә монумент-декоратив бизәкләү элементлары, мобиль һәм вертикаль яшелләндерү җайланмалары, су җайланмалары, муниципаль мебель, коммуналь-көнкүреш һәм техник җайланмалар. Кече архитектура формаларын проектлаганда һәм сайлаганда сертификатлы эшләнмәләр каталогларын кулланырга.

**Яшелләндереп бизәкләү җайланмалары**

2.5.2. Мобиль һәм вертикаль яшелләндереп бизәкләү өчен түбәндәге төр җайланмаларны кулланырга киңәш ителә: рәшәткәләр, үрелеп үсә торган үсемлекләр өчен баскычлар, үрмәләп үсә торган үсемлек әвеслекләре, чәчәклекләр, гөл чүлмәкләре. Рәшәткәләр һәм үрелеп үсә торган үсемлекләр өчен баскычлар – үрелеп яки терәлеп үсә торган үсемлекләр белән яшелләндерү өчен рәшәткә рәвешендәге җиңел агач яки металл конструкцияләр, тыныч ял почмакларын, кояштан ышыклану урыннарын ясау, мәйданчыкларны, техник җайланмаларны һәм корылмаларны киртәләү өчен кулланылырга мөмкин. Үрмәләп үсә торган үсемлек әвеслекләре – чатыр, галерея яки әвеслек рәвешендә агачтан яки металлдан эшләнә торган җиңел рәшәткә җайланмалары, «яшел тоннель», мәйданчыклар яки архитектура объектлары арасындагы кичү буларак кулланыла. Чәчәклекләр, гөл чүлмәкләре – үсемлек грунты белән зур булмаган савытлар, аларга чәчәк үсемлекләре утыртыла.

**Су җайланмалары**

2.5.3. Су җайланмаларына фонтаннар, эчә торган фонтанчыклар, бюветлар, чишмәләр, декоратив сулыклар керә. Су җайланмалары декоратив-эстетик функцияне башкара, микроклиматны, һава һәм акустика тирәлеген яхшырта. Барлык төр су җайланмаларын су агыза торган, артык суны читкә дренаж челтәренә һәм явым-төшем канализациясенә җибәрә торган трубалар белән җиһазларга кирәк.

2.5.3.1. Фонтаннарны хосусый проект эшләнмәләренә нигезләнеп проектларга киңәш ителә.

2.5.3.2. Эчә торган фонтанчыклар типик та, махсус башкарылган проект буенча да ясалырга мөмкин, аларны ял зоналарында урнаштырырга кирәк һәм спорт мәйданчыкларында – киңәш ителә. Эчә торган фонтанчык урнаштыру урынын һәм аңа бара торган юлны каты түрдәге түшәмә белән түшәргә кирәк, аның биеклеге өлкәннәр өчен 90 см биегрәк булырга һәм балалар өчен 70 см артмаска тиеш.

2.5.3.3. Шунысын исәпкә алырга кирәк: авыл җирлеге территориясендәге чишмәләр СанПиН таләпләренә ярашлы рәвештә су сыйфатына туры килергә һәм санитар-эпидемиологик күзәтчелек органнарыннан уңай бәяләмә алырга тиеш, табигый комплекслы махсус саклануучы территорияләрдә чишмә ясаганда, югарыда аталган бәяләмәдән тыш, табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча вәкаләтле органнардан рөхсәт алу таләп ителә. Чишмәләрне каты түшәмәле килү юлы һәм мәйданчыгы белән, чишмә суын бирү җайланмасы (улак, труба, башка төрле су агыза торган җайланма) белән, су алу чынаягы, су агызу системасы белән җиһазларга киңәш ителә.

2.5.3.4. Декоратив сулыкларны рельефтан файдаланып яки тигез өслектә газон белән берләштереп, плитә түшәмәсе, чәчәклекләр, агач-куак утыртмалары белән корырга киңәш ителә. Сулыкның төбе шома, чистарту өчен җайлы булырга тиеш. Чәчәкле һәм төсле бизәлеш алымнарыннан файдаланырга киңәш ителә.

**Мебель**

2.5.4. Үчәлле авыл җирлеге мебеленә (муниципаль мебель) түбәндәгеләр карый:

җәмәгать транспорты, рекреация һәм ишегалды территорияләрендә урнаштырыла торган төрле төрдәге ял итү эскәмияләре;

эскәмияләр һәм өстәлләр – өстәл уеннары, җәйге кафе һ.б. мәйданчыкларында.

2.5.4.1. Эскәмияләрне каты түшәмәле урыннарга яки фундаментка урнаштырырга. Ял итү, урман-парк, балалар мәйданчыклары зоналарында эскәмияләрне йомшак төрле түшәмәләргә урнаштырырга рөхсәт ителә. Фундамент булганда, аның өлешләрен җир өслегенә чыгып тормаслык итеп ясарга кирәк. Өлкән кешегә ял итү өчен эскәмия биеклеге юл түшәмәсе өслегеннән башлап яссы утыру өлешенә кадәр – 420-480 мм. Ял итү эскәмиясенең өслеген агачтан, суга каршы торырлык итеп төрлечә эшкәртеп ясарга киңәш ителә (барыннан бигрәк яклагыч состав белән).

2.5.4.2. Урнаштырыла торган муниципаль мебель саны территориянең функциональ билгеләнешенә һәм әлеге территориягә килүчеләр санына карап билгеләнә.

**Урамдагы коммуналь-көнкүреш җайланмалары**

2.5.3. Урамдагы коммуналь-көнкүреш җайланмалары гадәттә чүп җыя торган савытларның – контейнерларның һәм чүп савытларының төрле төрләреннән гыйбарәт. Теге яки бу коммуналь-көнкүреш җайланмасын сайлаганда төп таләпләр булып түбәндәгеләр тора: экологиялелек, куркынычсызлык (очлы почмакларының булмавы), файдаланудагы җиңеллеге,

чистарту җиңеллеге, күркәм тышкы кыяфәте.

2.5.3.1. Көнкүреш чүбен җыю өчен урамнарда, мәйданнарда, рекреация объектларында кечкенә габаритлы (кече) контейнерларны (0,5 куб. м. азрак) һәм (яки ) чүп савытларын кулланырга, аларны сәүдә һәм җәмәгать туклануы объектларына, иҗтимагый билгеләнештәге башка учреждениеләргә, торак йортларга һәм транспорт корылмаларына (автобус тукталышлары) керә торган урыннарда урнаштырырга кирәк. Кече контейнерларны һәм чүп савытларын (югарыда саналган объектлар янында мәҗбүри урнаштыруны исәпкә алмыйча) урнаштырганда интервал түбәндәгечә булырга тиеш: төп җәяүле коммуникацияләрендә – 60 м артык түгел, авыл җирлегендәге башка территорияләрдә – 100 м артык түгел. Рекреация объектлары территориясендә кече контейнерларны һәм чүп савытларын эскәмияләр, капиталь стационар булмаган корылмалар һәм урамдагы, туклану продуктларын сатуга юнәлдерелгән техник җайланмалар янәшәсендә урнаштыруны күздә тотарга кирәк. Барлык очракларда да җәяүлеләргә, инвалид һәм бала коляскалары белән йөрүгә комачауламаслык итеп урнаштыруны күздә тотарга.

**Урамдагы техник җайланмалар**

2.5.4. Урамдагы техник җайланмаларга түбәндәгеләр карый: таксофон корылмалары, почта әрҗәләре, су һ.б. сатучы автоматлар, сәүдә палаткалары, инженер җайланмасы элементлары (инвалид коляскаларын күтәртү мәйданчыклары, карый торган люклар, яңгыр суларын кабул итү коеларының рәшәткәләре, җир асты коммуникацияләренең җилләтү шахталары, телефон элемтәсе шкафлары һ.б.).

2.5.4.1. Урамда техник җайланма урнаштыру җайланмага уңайлы килү урынын тәэмин итәргә һәм 3 СНиП 35-01 бүлегенә туры киләргә тиеш.

2.5.4.2. Иҗтимагый, торак, рекреация билгеләнешендәге территорияләрдә таксофоннар урнаштырганда аларны электр белән яктыртуны күздә тотарга киңәш ителә. Таксофоннар урнаштыру урыннарын телефон канализациясе каналының (труба) салынма җайланмаларына тоташу урыннарыннан һәм электр белән тәэмин итү өчен каналдан (трубадан) максималь якын тирәдә проектларга кирәк. Таксофоннарны тимер акча кабул итү ярыгының түшәмә өслегеннән 1,3 м тәшкил итәрлек биеклектә; почта әрҗәсенең кабул итү ярыгын түшәмә өслегеннән 1,3 м биеклектә урнаштырырга.

2.5.5. Инженерлык җайланмалары элементларын ясау формалаштырыла торган тирәлекнең төзекләндерелү дәрәҗәсен бозарга, хәрәкәт итү шартларын начарайтырга, техник шартларга каршы килергә тиеш түгел, шул исәптән:

– җәяүле коммуникацияләре (шул исәптән урам юлларында) территориясендә урнашкан карау коеларының люк капкачларын чиктәш территорияләр түшәмәсе белән бер дәрәҗәдә проектларга кирәк, яки тамгаларның аерылып тора торган өлеше 20 мм артмаска, ә люк кырые белән тротуар түшәмәсе арасындагы аралыклар – иң күбе 15 мм;

– вентиляция шахталарын рәшәткәләр белән җиһазларга.

2.6. Уен һәм спорт җайланмалары.

2.6.1. Авыл җирлеге территориясендә уен һәм спорт җайланмалары уен,

физик культура-савыктыру җайланмаларыннан, корылмаларыннан һәм (яки) аларның комплексларыннан гыйбарәт булырга мөмкин. Балалар һәм яшүсмерләр өчен уен һәм спорт җайланмалары составын сайлаганда җайланманың төрле яшь төркемнәренең анатомик-физиологик үзенчәлекләренә (әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтаның 13 нче таблицасы) ярашуын тәэмин итәргә кирәк.

**Уен җайланмасы**

2.6.2. Шунысын исәпкә алырга кирәк: уен җайланмасы санитар-гигиена нормаларына, баланың гомерен һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә җавап бирергә, техник эксплуатациядә уңайлы, эстетик күркәм булырга тиеш. Элементларның бәйләнеш вариантларын тәэмин итә торган модульле җайланма кулланырга тәкъдим ителә.

2.6.3. Уен җайланмалары материалына һәм аны эшкәртү шартларына карата таләпләр:

– каты токымлы агачтан ясалган, черүгә, коруга, янып китүгә, ярылуга каршы махсус эшкәртелгән агач җайланма; шомартылган, очлы почмаклары йомрыландырылган;

– металл өстенлекле рәвештә терәк булып торучы җайланма конструкцияләре өчен, ялгану өлешләре ышанычлы һәм тиешенчә эшкәртелгән булырга тиеш (суга чыдарлык итеп буялган, тутыгуга каршы тышча белән капланган); металл-пластик кулланырга киңәш ителә (җәрәхәтләми, тутыкмый, кышкы салкыннарга чыдам);

– җайланмаларның бетон һәм тимер-бетон элементлары кимендә 300 маркалы, кимендә 150 салкыннарга чыдамлы, шома өслекле бетоннан ясалган булырга тиеш;

– пластик һәм полимер җайланмалар шома өслекле һәм якты, климат факторлары тәэсирендә уңмый торган чиста буяу төсләре гаммасы белән ясалырга тиеш.

2.6.4. Уен җайланмалары конструкцияләренә булган таләпләрдә очлы почмакларны, баланың тәне кысылып калырга мөмкин булган урыннарны, аларның хәрәкәт итү торышында җайланма элементларына эләгүен булдырмаска кирәк; җайланма тоткычлары тулысынча бала кулы белән тотарлык булырга тиеш; балаларга ашыгыч ярдәм күрсәтү өчен уен җайланмалары комплексларына, эчке тирәлек тирәнлеге 2 м артык булганда, кимендә 500 мм диаметрындагы тишекләр (кимендә ике) рәвешендә эчкә үтеп керү мөмкинлеген калдыруны күздә тотарга кирәк.

2.6.5. Балаларның уен мәйданчыкларына уен җайланмаларын урнаштырганда әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтаның 15 нче таблицасына туры китереп, минималь куркынычсызлык аралыкларын сакларга кирәк. Аталган аралыклар чигендә мәйданчык территориясе урыннарында башка төрле уен җайланмаларын, эскәмияләр, чүп савытлары, борт ташлары һәм каты төрдәге түшәмәләр, шулай ук ботаклар, кәүсәләр, агач тамырлары урнаштыру рөхсәт ителми. Уен җайланмалары һәм аның аерым өлешләре параметрларына карата таләпләр әлеге Кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасындагы 14 нче таблицада

күрсәтелде.

**Спорт җайланмалары**

2.6.6. Халыкның барлык яшьтәге төркемнәре өчен билгеләнгән спорт җайланмалары спорт, физик культура мәйданчыкларына яисә рекреацияләр составында махсус җиһазландырылган җәяүле коммуникацияләрендә (сәламәтлек сукмаклары) урнаштырыла. Махсус физик культура снарядлары һәм тренажерлар рәвешендәге спорт җайланмасы заводта ясалган да булырга мөмкин, шулай ук өслегеи җәрәхәт алуны булдырмаслык итеп (ярыклары, китекләре һ.б. булмаслык итеп) махсус эшкәртелгән бүрәнәләрдән һәм борыслардан да эшләнергә мөмкин. Урнаштырганда сертификатлы җайланма каталогларына таянып эш итәргә кирәк.

2.7. Яктырту һәм яктырту җайланмалары.

2.7.1. Төрле шәһәр төзелеше шартларында утилитар, яктылыкны планлаштыру һәм яктылык композициясе бурычларын хәл итү максатында, шул исәптән авыл җирлеге территориясен яктылык-төс белән зоналарга бүлү һәм яктылык тирәлеге ансамбльләре системасын формалаштыру зарурлыгы булганда функциональ, архитектураны һәм мәгълүматларны яктыртуны күздә тотарга кирәк.

2.7.2. Яктырту җайланмаларының һәр төп төркемен (функциональ, архитектура яктырту, мәгълүмат яктырту) проектлаганда түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

– йортлар салу өчен билгеләнгән территорияләрне ясалма яктырту һәм тышкы архитектураны яктырту буенча гамәлдәге нормаларда каралган сан һәм сыйфат күрсәткечләрен (СП 5213330.2011 «СНиП 23-05-95. Табигый һәм ясалма яктырту);

– Электр җайланмаларын урнаштыру нормаларына туры китереп, җайланмаларның ышанычлы эшләвен, халыкның, хезмәт күрсәтүче персоналның иминлеген һәм, зарурлык булган очракларда, вандаллыкка каршы якланганлыкны;

– кулланыла торган җайланмаларның экономияле һәм энергия ягыннан нәтиҗәле булуын, электр энергиясенең рациональ бүленешен һәм файдаланылуын;

– яктырткыч җайланма элементларының эстетикасын, аларның дизайнын, көндезге һәм төнге вакытта кабул итүне исәпкә алып, материалларның һәм эшләнмәләрнең сыйфатын;

– җайланмаларның төрле эш режимнарында хезмәт күрсәтүенең һәм аларга идарә итүнең уңайлылыгын.

**Функциональ яктырту**

2.7.3. Функциональ яктырту (ФЯ) юл өслекләрен һәм транспорт һәм җәяүле зоналарындагы тирәлекләрне станционар җайланмалардан яктыртып гамәлгә ашырыла. ФЯ җайланмалары, кагыйдә буларак, гадәти, югары мачталы, парапетлы, газонлы һәм кертеп корылган була.

2.7.3.1. Гадәти җайланмаларда яктырткычларны баганаларга (кидереп куела торган, консольле), элгечләргә яки фасадларга (бра, плафоннар) 3 м алып

15 м кадәр биеклектә урнаштырырга. Аларны иң гадәти буларак транспорт һәм җәяүле зоналарында кулланырга киңәш ителә.

2.7.3.2. Югары мачталы җайланмаларда яктырту җиһазларын (прожекторларны яки яктырткычларны) 20 м һәм аннан биегрәк булган баганаларга урнаштырырга. Әлеге җайланмаларны киң тирәлекләрне, борылышларны һәм магистральләрне, ачык паркингларны яктырту өчен кулланырга киңәш ителә.

2.7.3.3. Парапет җайланмаларындагы яктырткычларны линияләп яки пунктирлап, юлүткәргечләрнең юл өлешен, күперләрне, эстакадаларны, пандусларны, борылышларны, шулай ук тротуарларны һәм мәйданчыкларны киртәләп торучы 1,2 метрга кадәрле биеклектәге парапетка урнаштырырга киңәш ителә. Аларның кулланылышы техник-икътисадый һәм (яки) сәнгать аргументлары белән нигезләнә.

2.7.3.4. Газон яктырткычлары газоннарны, чәчәклекләрне, җәяүле юлларын һәм мәйданчыкларны яктырту өчен хезмәт итә. Алар иҗтимагый тирәлек һәм рекреация объектлары территорияләрендә минималь вандаллык зоналарында күздә тотылырга мөмкин.

2.7.3.5. Баскычларга, терәүле диварчыкларга, коймаларга, бина һәм корылма цокольләренә, КАФ беркетелгән яктырткычларны иҗтимагый билгеләнештәге территорияләрдә җәяүле зоналарын яктырту өчен кулланырга киңәш ителә.

Архитектура яктырту

2.7.4. Архитектураны яктыртуны (АЯ) кичен сәнгатьле ачык визуаль тирәлекне формалаштыру, архитектура, тарих һәм мәдәният, инженер һәм монумент сәнгате һәйкәлләрен, КАФ, доминант һәм исәтлекле объектларны, ландшафт композицияләрен караңгыда абайлау һәм образлы интерпретацияләү, төсләр ансамблен тудыру өчен кулланырга киңәш ителә. Ул гадәттә объектларны стационар яки вакытлыча яктырту җайланмалары ярдәмендә, иң әүвәл, аларның фасад өслекләрен тыштан яктырту юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.7.4.1. Вакытлыча АЯ җайланмаларына бәйрәм иллюминациясе керә: утлы гирляндалар, ятьмәләр, контур тышлыклары, яктыртучы графика элементлары, панно һәм яктыртучы, разрядлы, светодиод лампаларыннан күләмле композицияләр, яктырту проекцияләре, лазерлы рәсемнәр һ.б.

2.7.5. Архитектураны яктырту максатларында шулай ук ФЯ җайланмалары да кулланылырга мөмкин – биналарның, корылмаларның, яшел утыртмаларның фасадларына төбәлә торган прожекторларны монтажлау өчен, иллюминацияләү, яктыртылучы мәгълүмат һәм реклама өчен, аларның элементлары урам яктырткычлары баганаларына беркетелергә мөмкин.

**Мәгълүмат яктырту**

2.7.6. Мәгълүматны яктырту (МЯ), шул исәптән, рекламаны яктырту җәяүлеләргә һәм автотранспорт йөртүчеләргә тирәлектә юнәлеш алырга ярдәм итәргә һәм яктыртучы-композиция бурычларын хәл итүдә катнашырга тиеш. Мондый мәгълүмат элементларын урнаштыруны, аларның габаритларын,

формаларын һәм яктыртучы төсе буенча исәпләнгән аралыклардан кабул итү төгәллеген һәм гамәлдәге Юл хәрәкәте кагыйдәләренә каршы килми торган, халыкка яшәү уңайлыгын бозмый торган төсләр ансамбленең гармониялелеген тәэмин итүче параметрларын исәпкә алырга киңәш ителә.

Яктырту чыганаклары

2.7.7. Стационар ФЯ һәм АЯ җайланмаларында энергия агыннан нәтиҗәле яктырту чыганакларын, нәтиҗәле яктырту җиһазларыннан һәм системаларыннан, дизайны һәм эксплуатацияләү сыйфатламалары буенча сыйфатлы эшләнмәләрдән һәм материаллардан: гамәлдәге илкүләм стандартларның таләпләренә җавап бирә торган баганалардан, кронштейннардан, яклагыч рәшәткәләрдән, экраннардан һәм конструктив элементлардан файдаланырга киңәш ителә.

2.7.8. ФЯ җайланмаларыннан яктырту чыганакларын таләпләрне, юнәлеш алуны яхшыртуны, уңайлыклы күренеш шартларын формалаштыруны, шулай ук, зарурлык булган очракта, яктыртучы төс белән зоналарга бүленешне исәпкә алып сайларга киңәш ителә.

2.7.9. АЯ һәм МЯ җайланмаларында формалаштырыла торган яктылык һәм төс адаптациясе шартларын һәм барлык төркемнәрдәге яктырту җайланмаларының, аеруча торак пунктының конкрет тирәлегендә функцияләүче хроматик утның яки утлар ансамбленең уртак тәэсире белән булдырыла торган суммар күренеш нәтиҗәсен исәпкә алган ак яки төсле яктырту чыганакларыннан файдаланырга киңәш ителә.

**Транспорт һәм җәяүле зоналарын яктырту**

2.7.10. Транспорт һәм җәяүле зоналарындагы ФЯ җайланмаларында туры, чәчмә яки чагылдыра торган утның түбәнге ярымсферасына юнәлдерелгән яктырту җиһазларын кулланырга. Яктылык бүленеше чикләнмәгән яктырткычларны (үтәкүренмәле яки яктылык чәчә торган материалдан шарлар тибында) газоннарда, фасадларда (бра яки плафон тибында) һәм киертеп куела торган һәм консоль җиһазлары булган баганаларга урнаштырырга рөхсәт ителә. Соңгыларын яшелләндерелгән территорияләргә яки яктыртылган биналарның, корылмаларның фасадлары, рельеф таулары фонында урнаштырырга киңәш ителә.

2.7.11. Урамнарның юл өлешен һәм алар белән янәшә торган тротуарларны яктырту өчен җәяүлеләр интенсив хәрәкәт иткән зоналарда төрле биеклектәге, утның төрле спектр чыганаклары белән тәэмин ителгән яктырткычлы ике консольле баганаларны кулланырга киңәш ителә.

2.7.12. Транспорт һәм җәяүле зоналарында ФЯ яктырткычларының тибын, аларны урнаштыру урынын һәм ысулын яктылык тирәлегенең формалаша торган күләмен исәпкә алып сайларга киңәш ителә. Урамнарның, юлларның һәм мәйданнарның юл өслегендә яктырткычларны кимендә 8 м биеклектәге баганаларга урнаштырырга кирәк. Җәяүле зоналарында яктырткычларны баганаларга урнаштыру биеклеге – кимендә 3,5 м һәм иң күбе 5,5 м. Юлларны, тротуарларны һәм биналар янындагы мәйданчыкларны яктырту өчен яктырткычларны (бра, плафоннар) кимендә 3 м биеклегендә

урнаштырырга кирәк.

2.7.13. Магистраль урамнарның (районнарның) юл өлешен яктырту өчен урам яктырткычлары баганалары борт ташының тышкы чигеннән багана цоколенә кадәр кимендә 0,6 м ераклыкта урнаша ала, җирле әһәмияттәге урам челтәрендә автобус хәрәкәте булмау, шулай ук йөк машиналарының даими йөрмәү шарты белән, әлеге аралыкны 0,3 м кадәр киметергә рөхсәт ителә. Багана янгын гидранты белән урманраның һәм юлларның йөри торган өлеше арасында урнашырга тиеш түгел.

2.7.14. Магистраль урамнар һәм юллар кисешкән урыннардагы баганалар, кагыйдә буларак, тротуарлар түгәрәкләнә башлаганчы ук һәм төрле төрдәге чыгу юлларына кадәр, аларны урнаштыру линиясенең бердәм сафын бозмыйча, кимендә 1,5 м ераклыкта урнаша.

**Яктырту җайланмаларының эш режимнары**

2.7.15. Яктырту җайланмаларының барлык өч төркемен дә (ФЯ, АЯ, МЯ) проектлаганда электр энергиясеннән рациональ файдалану һәм торак пунктында тәүлекнең төнге чорында визуаль төрлелекне тәэмин итү максатларында аларның түбәндәгечә эш режимнарын күздә тотарга кирәк:

– кичке көндәлек режим, бу вакытта барлык ФЯ, АЯ, МЯ станционар җайланмалары да эшли, бәйрәмчә яктырту системаларыннан тыш;

– төнге кизү режимы, бу вакытта ФЯ, АЯ һәм МЯ җайланмаларында яктыртучы җиһазларның бер өлеше яктырту нормаларында рөхсәт ителгәнчә һәм авыл хакимияте боерыклары нигезендә сүндерелергә мөмкин;

– бәйрәм режимы, бу вакытта өч төркемнең барлык стационар һәм вакытлыча яктырту җайланмалары да авыл хакимияте билгели торган тәүлек сәгатьләрендә һәм атна көннәрендә эшли;

– сезонлы режим, иң әүвәл ФЯ һәм АЯ стационар һәм вакытлыча җайланмалары өчен билгеле бер срокларда (кышын, көзен) рекреация зоналарында күздә тотыла.

2.7.16. Яктыртучы җайланмаларның барлык төркемнәре дә, аларның кайсы ведомствоныкы булуына бәйсез рәвештә, табигый яктылык дәрәҗәсе 20 лк кадәр кимегәндә кичен кабызылырга мөмкин.

Сүндерүне түбәндәгечә башкарырга:

– ФЯ җайланмаларын – иртән, яктылык дәрәҗәсе 10 лк кадәр артканда; кичке режимнан төнге режимга күчергәндә урам утларын сүндерү мөмкин булган вакыт авыл җирлеге хакимияте тарафыннан билгеләнә;

– АЯ җайланмаларын – авыл җирлеге хакимияте карары нигезендә, анда яктыртыла торган күпчелек объектлар өчен кышкы һәм җәйге яртыеллыкта кичке режим тиешенчә төнге уникегә кадәр һәм төнге бергә кадәр билгеләнә, ә кайбер объектларда (шәһәр төзелеше доминантлары һ.б.) АЯ җайланмалары кояш батканнан алып таң атканчыга кадәр эшләргә мөмкин;

– МЯ җайланмаларын – тиешле ведомстволарның яки хуҗаларының карары буенча.

2.8. Тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары.

2.8.1. Тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын торак пункты

территориясендә ГОСТ Р 52044 туры китереп урнаштырырга кирәк.

2.9. Капиталь һәм стационар булмаган корылмалар.

2.9.1. Җиңел конструкцияләрдән ясалган, тирәнәйтелгән фундаментлар һәм җир асты корылмалары урнаштыруны күздә тотмый торган корылмалар ныклап төзелмәгән стационар булмаган корылмалар була – болар ваклап сәүдә итүче, юл буенда көнкүреш хезмәтләре күрсәтүче һәм туклану объектлары, тукталыш павильоннары, җир өсте бәдрәф кабиналары, бокс гаражлары, капиталь булмаган холыклы башка объектлар. Корылмаларның тышкы төзекләндерү материаллары санитария-гигиена таләпләренә, янгын куркынычсызлыгы нормаларына, дизайны һәм яктыртылышы буенча архитектура-сәнгать таләпләренә, торак пунктының барлыкка килгән тирәлек холкына һәм озак вакытлы эксплуатацияләү шартларына җавап бирергә тиеш. Витриналарны пыяла белән тышлаганда китекләре булмаган, бәрелүгә чыдам материаллар, куркынычсыз күпкатлы ныгыта торган пленкалы тышчалар, поликарбонат пыялалар кулланырга кирәк. Мини-маркетлар, мини-базарлар, сәүдә рәтләрен проектлаганда җиңел конструкцияләрдән ясалучы тиз торгызыла торган модульле комплекслардан файдаланырга киңәш ителә.

2.9.2. Капиталь һәм стационар булмаган корылмаларны авыл җирлеге территориясендә урнаштыру җәяүлеләргә хәрәкәт итү өчен комачауларга, янгынга каршы таләпләрне бозарга, үзләре янәшәсендә урнашкан территориянең һәм бүлмәләрнең инсоляция шартларын бозарга, торак пунктындагы тирәлекне визуаль кабул итүне һәм территорияләрнең һәм төзеп тутырылган урыннарның төзеклеген начарайтырга тиеш түгел. Корылмаларны теркәлгән мәдәни мирас (табигый) һәйкәлләренең саклык зоналары чикләрендә һәм махсус саклanучы табигый территорияләрнең зоналарында урнаштырганда, корылмаларның параметрларын (биеклеге, киңлеге, озынлыгы), вазыйфаи билгеләнешен һәм аларны урнаштыру буенча башка шартларны һәйкәлләрне саклау, табигать саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча вәкаләтле органнар белән килештерергә кирәк.

2.9.2.1. Ныклап төзелмәгән стационар булмаган корылмаларны газоннарда, мәйданчыкларда (балалар, ял, спорт, транспорт тукталышлары), пассажир транспортына утыру мәйданнарында, суүткәргеч һәм канализация челтәрләренең, трубаүткәргечләрнең саклык зоналарында, шулай ук вентиляция шахталарына – 25 м, торак бина тәрәзәләре, сәүдә предприятиеләренең витриналары каршысында – 20 м, агач кәүсәсеннән 3 м якынрак урынга урнаштыру рөхсәт ителми.

2.9.3. Ваклап сәүдә итүче предприятиеләрнең, көнкүреш хезмәтләре күрсәтүче һәм туклану корылмаларын җәяүле зоналары территорияләрендә, паркларда, бакчаларда, торак пункты бульварларында урнаштырырга киңәш ителә. Корылмаларны түшәмәнең каты төрләренә урнаштырырга, яктырту җайланмалары, чүп өчен чүплек савытлары һәм кече контейнерлар белән, туклану корылмаларын бәдрәф кабиналары (чиктәш территориядә 200 м аралыгында җәмәгать бәдрәфләре булмаганда) белән җиһазларга.

2.9.4. Тукталыш павильоннарын җир өсте пассажир транспорты

тукталышы урыннарында урнаштыруны күздә тотарга кирәк. Павильонны урнаштыру өчен 2,0x5,0 м һәм аннан зуррак күләмдә түшәмәләрнең каты төре җәелгән мәйданны карарга кирәк. Юлның кырый өлешеннән павильонның иң якын конструкциясенә кадәрге аралык – кимендә 3,0 м, павильонның ян-як конструкцияләреннән агачлар кәүсәсенә булган аралык – җыйнак ябалдашлы агачлар өчен – кимендә 2,0 м. Тукталыш пунктларын проектлаганда һәм тукталыш мәйданчыклары коймаларын урнаштырганда тиешле ГОСТ һәм СНиП таянып эш итәргә кирәк.

2.9.5. Бәдрәф кабиналарын, җәмәгать бәдрәфләре булмаганда яки алардан файдалану мөмкинлеге җитәрлек булмаганда, торак пунктының кешеләр актив йөри торган территорияләрендә: массакүләм чаралар уздырылган урыннарда, сәүдә итүче һәм хезмәтләр күрсәтүче зур объектларда, рекреация объектлары территорияләрендә (паркларда, бакчаларда), автотукталышларда, шулай ук ныклап төзелмәгән стационар булмаган туклану корылмалары янында урнаштырырга киңәш ителә. Шунысын исәпкә алырга кирәк: бәдрәф кабиналарын йорт яны территориясендә урнаштырырга рөхсәт ителми, бу вакытта торак һәм җәмәгать биналарына кадәрле аралык кимендә 20 м калырга тиеш. Бәдрәф кабинасын түшәмәләрнең каты төрләренә урнаштырырга кирәк.

2.10. Биналарны һәм корылмаларны бизәү һәм җиһазлау.

2.10.1. Биналарны һәм корылмаларны бизәү һәм җиһазлау түбәндәгеләрне үз эченә ала: стеналарның тышкы өслекләрен төрле төсләргә буяу, түбә төзекләндерү, бинаның конструктив элементларын җиһазлауның кайбер мәсьәләләре (керү төркемнәре, цокольләр һ.б.), антенналар, су агызу трубалары, фундамент күперчекләре, йорт тамгалары, яклагыч ятьмәләр урнаштыру һ.б.

2.10.2. Биналарны һәм корылмаларны төрле төсләр белән буяуны Үчәлле авыл җирлегендә урамнарны һәм территорияләрне төзеп тутыруның гомуми төс чишелеше концепциясен исәпкә алып проектларга киңәш ителә.

2.10.2.1. Лоджияләрне һәм балконнарны пыяла белән тышлату, рам алмаштыру, торак пунктларындагы биналарның стеналарын буяу мөмкинлеге шәһәр төзелеше регламенты составында билгеләнә.

2.10.2.2. Торак пунктының магистраль урамнары буйлап урнашкан биналарга тышкы кондиционерларны һәм «тәлинкә»-антенналарны ишегалы фасадлары ягыннан урнаштыруны күздә тотарга киңәш ителә.

2.10.3. Торак пункты биналарында һәм корылмаларында түбәндәге йорт тамгаларын урнаштыруны күздә тотарга киңәш ителә: урамның, мәйданның, проспектның исемен күрсәткеч, йортның яки корпусның номерын күрсәткеч, подъездның һәм фатирның номерын күрсәткеч, объектның инвалидлар өчен үтемле булуының халыкара символы, флаг тоткычылар, истәлекле такталар, полигонометрик тамга, янгын гидрантына күрсәтү, грунт геодезия тамгаларын күрсәтү, магистраль камераларын һәм суүткәрү челтәрләре коелары күрсәткечләре, канализациягә күрсәтү, җир асты газүткәргеч корылмаларына күрсәтү. Билгеле бер бинада йорт тамгаларының составы һәм аларны урнаштыру шартлары биналарның вазыйфаи билгеләнеше һәм юл-урам челтәренә карата урнашуы нигезендә билгеләнә.

2.10.4. Биналардан һәм корылмалардан җир өслеге суларын читкә агызуны тәэмин итү өчен аларның периметры буенча ышанычлы гидроизоляцияле күперчекләр урнаштыру күздә тотыла. Күперчекнең авышлыгы – бина ягыннан кимендә 10%. Биналар һәм корылмалар өчен күперчек киңлеге – 0,8-1,2 м, катлаулы геология шартларында (карстлы грунтлар) – 1,5-3 м. Бина җәяүле коммуникацияләренә тоташкан очракта, гадәттә түшәмәнең каты төре белән ясалган тротуар күперчек ролен башкара.

2.10.5. Тигез түбәләрдән җыелган суны шуның өчен билгеләнгән трубадан агызуны оештырганда:

– бина стеналарына трубалар урнаштырганда фасадларның пластикасын бозмаска, ялгап тоташтыру урыннарының герметиклы булуын һәм, су агынтысының исәпләнгән күләмнәреннән чыгып, таләп ителгән үткәрү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

– трубаның чыгып тора торган тишегеннән суның ирекле агып төшү биеклегенең 200 мм артык булуына юл куймаска;

– трубадан төп җәяүле коммуникацияләренә су агып төшкән урыннарда су агызу улаклары юнәлешендә кимендә 5% авышлыгында каты түшәмә җәелүен, яки улакларның каплавыч эчендә (әлеге Кагыйдәләрнең 2.1.14 пунктына туры китереп, ябык яки рәшәткәләр белән ябылган) урнаштырылуын күздә тотарга;

– трубадан газонга яки түшәмәнең йомшак төрләренә су агып төшкән урыннарда дренаж урнаштыруны күздә тотарга.

2.10.6. Торак һәм иҗтимагый билгеләнештәге биналарның керү төркемнәрен яктыртучы җайланма, әвеслек (каплап торучы ярымтүбә), өслекләрне тоташтыру элементлары (басмалар һ.б.), инвалидларга һәм халыкның азмобильлекле төркемнәренә хәрәкәт итү җиһазлары һәм җайланмалары (пандуслар, тоткычлар һ.б.) белән тәэмин итәргә киңәш ителә.

2.10.6.1. Керү төркемнәре янәшәсендә түшәмәнең каты төрләре һәм яшелләндерүнең төрле алымнары кулланылган мәйданчыкларны күздә тотарга. Керү өлешендә мәйданчыкларны оештыру әлеге урын территориясе чикләрендә дә, шулай ук торак пунктының керү төркемнәренә чиктәш булган иҗтимагый территорияләрендә дә каралырга тиеш.

2.10.6.2. Керә торган төркемнәр янәшәсендәге мәйданчыкның бер өлешендә җиңел транспортны вакытлыча кую рөхсәт ителә, әгәр бу вакытта җәяүлеләр агымын үткәреп җибәрү өчен кирәкле юл киңлеге тәэмин ителсә, анысы исәпләмә белән раслана (әлеге Кагыйдәләргә 3 нче кушымта). Бу очракта бүлеп тора торган элементлар (стационар яки күчмә коймалар) булуын, контейнер яшелләндерүне күздә тотарга кирәк.

2.10.6.3. Керә торган төркемнәрне тротуарның минималь норматив киңлеге белән урам-юл челтәре тротуарлары зонасында урнаштырган очракта, керү төркемнәре элементларын (басмаларны, падусларны, болдырны, яшелләндерүне) 0,5 м артмаган аралыкка янәшә торучы тротуарга чыгарырга.

2.10.7. Җәяүлеләрне һәм чыгып тора торган пыяла витриналарны түбә кырыеннан кар һәм боз сөңгеләре ишелеп төшүдән, шулай ук 70 нче елларга

кадәр төзелгән чоргы аерым биналарның стеналарыннан тышлагыч плитәләр очып төшүдән саклау өчен икенче кат дәрәҗәсендә махсус яклагыч ятьмәләр урнаштыруны күздә тотарга кирәк. Боз сөңгеләре барлыкка килүне булдырмас өчен түбәнең тышкы периметры буйлап электр контурын кулланырга киңәш ителә.

2.11. Мәйданчыклар.

2.11.1. Торак пункты территориясендә мәйданчыкларның түбәндәге төрләрен проектларга киңәш ителә: балаларга уйнау өчен, өлкәннәргә ял итү өчен, спорт белән шөгыльләнү, чүп җыя торган савытлар урнаштыру, этләрне йөртеп керү һәм күнекмәләргә өйрәтү, автомобильләр куюю өчен.

**Балалар мәйданчыклары**

2.11.2. Балалар мәйданчыклары төрле яшьтәге балаларга уйнау һәм актив ял итү өчен билгеләнгән: мәктәп алды яшендәге (3 яшькә кадәрле), мәктәпкәчә яшьтәге (7 яшькә кадәр), кече һәм урта мәктәп яшендәге (7-12 яшь). Мәйданчыклар төрле яшь төркемнәре өчен аерым мәйданчыклар рәвешендә яки яшь мәнфәгатьләре буенча зоналарга аерылган комплекслы уен мәйданчыклары рәвешендә дә оештырылырга мөмкин. Балалар һәм яшүсмерләр (12-16 яшь) өчен спорт-уен комплексларын (микроскалодромнар, велодромнар һ.б.) оештырырга һәм самокатларда, тәгәрмәчле такталарда һәм тимераякларда йөрү өчен махсус урыннар җиһазларга киңәш ителә.

2.11.3. Торак йортларның һәм иҗтимагый биналарның тәрәзәләреннән мәктәпкәчә яшьтәге балалар мәйданчыклары чикләренә кадәрле аралыгы кимендә 10 м, кече һәм урта мәктәп яшендәгеләр өчен – кимендә 20 м, комплекслы уен мәйданчыкларыннан – кимендә 40 м, спорт-уен комплексларыннан – кимендә 100 м. Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәгеләр өчен балалар мәйданчыкларын тораклар төзелгән урында урнаштырырга, кече һәм урта мәктәп яшендәге балалар мәйданчыкларын, комплекслы уен мәйданчыкларын торак төркеменең яки микрорайонның яшелләндерелгән территорияләрендә, спорт-уен комплексларын һәм тәгәрмәчле җайланмаларда йөрү урыннарын торак район паркларында урнаштырырга киңәш ителә.

2.11.4. Торак билгеләнешендәге территорияләрдә балалар өчен уен мәйданчыкларын 1 кешегә 0,5-0,7 кв. м. исәбеннән проектларга киңәш ителә. Мәйданчыкларның зурлыкларын һәм аларны урнаштыру шартларын балаларның яшь төркемнәренә һәм төзелгән торакларның урнашу урынына карап проектларга киңәш ителә.

2.11.4.1. Мәктәп алды яшендәге балалар мәйданчыклары зур булмаска (50-75 кв.м.), аерым яки өлкәннәр өчен тыныч ял урыннары белән бергә урнаштырылырга мөмкин – бу очракта мәйданчыкның гомуми мәйданын кимендә 80 кв. метр итеп билгеләргә киңәш ителә.

2.11.4.2. Уен мәйданчыкларының оптималь зурлыгын мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен 70-150 кв.м, мәктәп яшендәгеләр өчен 100-300 кв.м, комплекслы уен мәйданчыклары өчен 900-1600 кв. м күләмендә билгеләргә киңәш ителә. Бу вакытта мәктәпкәчә яшьтәгеләр мәйданчыгын өлкәннәрнең ял мәйданчыгы белән берләштерергә мөмкин (мәйданчыкның зурлыгы – кимендә

150 кв.м.). Күрше булып торучы балалар һәм өлкәннәр мәйданчыкларын куе яшел утыртмалар һәм (яки) декоратив диварлар белән аерырга.

2.11.5. Балалар мәйданчыклары транзит җәяүле хәрәкәтеннән, юллардан, борылыш ясау мәйданчыкларыннан, килгән-киткән машиналар туктап тора торган урыннардан, чүп җыю савытлары урнаштырыла торган мәйданчыклардан, автотранспорт чараларын даими һәм вакытлыча саклау урыннарыннан изоляцияләнгән булырга тиеш. Балалар мәйданчыкларына бара торган юлларны машина юлларыннан һәм урамнардан оештырмаска кирәк. Балалар мәйданчыкларын яшел утыртмалар (агачлар, куаклыклар) белән аерып алганда, балалар мәйданчыгы чикләреннән килгән-киткән машиналар туктала торган урынга һәм автотранспорт чараларын даими һәм вакытлыча саклау урыннарына кадәр минималь аралыгын СанПиН туры китереп билгеләргә кирәк, чүп җыю мәйданнарына кадәр – 15 м.

2.11.6. Балалар мәйданчыкларын реконструкцияләгәндә травматизм алуны булдырмас өчен мәйданчык территориясендә чыгып тора торган ботакларны яки сыгылып төшкән тәбәнәк ботакларны, җир өслегендә торган иске, кисек җайланма калдыкларын (баганалар, фундаментлар), җиргә күмелмәгән, кагыйдә буларак, турникларны һәм таганнарны беркетүче металл җайланмаларны калдырмаска кирәк. Янәшә торучы территорияләрне реконструкцияләгәндә балалар мәйданчыкларын эшләр алып барылган урыннардан һәм төзелеш материаллары өелә торган җирләрдән изоляцияләргә кирәк.

2.11.7. Балалар мәйданчыгында территорияне төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: түшәмәләрнең йомшак төрләре, мәйданчык өслегенең газонга тоташу элементлары, яшеллек, уен җайланмалары, эскәмияләр һәм чүп савытлары, яктырту җайланмалары.

2.11.7.1. Түшәмәләрнең йомшак төрләрен (ком, грунт нигезендә яки гравий кыйпылчыкларында тыгызландырылган ком, йомшак резин яки йомшак синтетик) балалар мәйданчыгының уен җайланмалары урнаштырылган урыннарга һәм балалар егылырга мөмкин булган башка урыннарга җәяргә кирәк. Эскәмияләр урнаштырылган урыннарны әлеге Кагыйдәләрнең 2.6.4.1 пункты нигезендә түшәмәнең каты төрләре яки фундамент белән җиһазларга. Мәйданчыклар өслеген үлән белән каплаганда каты, йомшак яки катнаш түшәмә төрләреннән ясалган җәяүле юлларын күздә тотарга.

2.11.7.2. Мәйданчык өслекләрен һәм газоннарны тоташтыру өчен чабылган яки йомрыландырылган кырыйлы бакча борт ташларын кулланырга.

2.11.7.3. Балалар мәйданчыкларын, көннең якты өлешендә 5 сәгать эчендәге инсоляцияне исәпкә алып, агачлар һәм куаклар утыртып яшелләндерергә. Мәйданчыкның көнчыгыш һәм төньяк өлешләрендәге агачлар мәйданчык кырыеннан алып агач үзәгенә кадәр 3 метрдан якынрак булмаган аралыкта, ә көньяк һәм көнбатыш өлешләрендә 1 метрдан якынрак булмаган аралыкта утыртылырга тиеш. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар мәйданчыкларында чәнечкеле үсемлек төрләрен кулланырга ярамый. Бөтен төр балалар мәйданчыкларында агулы җимеш бирә торган үсемлекләрне кулланырга

ярамый.

2.11.7.4. Уен җайланмалары урнаштыруны әлеге Кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасындагы 14 нче таблицасында күрсәтелгән куркынычсызлыкның норматив параметрларын исәпкә алып проектларга кирәк. Спорт-уен комплекслары мәйданчыкларын Мәйданчыкта үз-үзеңне тоту һәм спорт-уен җайланмаларыннан файдалану нормалары эленгән стенд белән җиһазларга.

2.11.7.5. Яктырткыч җайланмалар мәйданчык урнашкан территорияне яктырту режимында эшләргә тиеш. Яктырту җайланмасын 2,5 метрдан тәбәнәгрәк итеп урнаштырырга рөхсәт ителми.

**Ял мәйданчыклары**

2.11.8. Ял мәйданчыклары гадәттә өлкән халык өчен тынычлап ял итү һәм өстәл уеннары уйнау өчен билгеләнә, аларны тораклар төзелгән урыннарда урнаштырырга кирәк, торак төркемнәренең һәм микрорайонның яшелләндерелгән территорияләрендә, паркларда һәм урман-паркларда рөхсәт ителә. Ял мәйданчыкларын үтеп йөрерлек итеп, подъездларга, тукталышта утыру мәйданчыкларына, транспорт чаралары борылыш ясый торган мәйданчыкларга тоташтырып урнаштырырга – алар белән ял мәйданчыклары арасында кимендә 3 м яшеллек полосасын (куаклык, агачлар) күздә тотарга киңәш ителә. Ял мәйданчыгы чигеннән автомобильләрне саклау урыннарына кадәрге аралыкны СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200 туры китереп кабул итәргә. Торак йортлар тәрәзәләреннән тынычлап ял итү мәйданчыклары чигенә кадәрге аралык кимендә 10 м тәшкил итәргә тиеш, шау-шулы өстәл уеннары мәйданчыкларына кадәр – кимендә 25 м.

2.11.9. Торак территорияләрдәге ял мәйданчыкларын бер кешегә 0,1-0,2 кв.м исәбеннән проектларга кирәк. Мәйданчыкның оптималь зурлыгы 50-100 кв.м, ял мәйданчыгының минималь зурлыгы – кимендә 15-20 кв.м. Әлеге Кагыйдәләрнең 2.12.4.1 пункты нигезендә тынычлап ял итү мәйданчыкларын балалар мәйданчыклары белән берләштерергә рөхсәт ителә. Тынычлап ял итүне һәм шау-шулы өстәл уеннарын бер мәйданчыкка урнаштырырга киңәш ителми. Парклар территорияләрендә үләндә ял итү өчен чирәмлек мәйданчыкларын оештырырга киңәш ителә.

2.11.10. Ял итү мәйданчыгында төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: түшәмәләрнең каты төрләре, мәйданчык өслеген газонга тоташтыру элементлары, яшеллек, ял эскәмияләре, эскәмияләр һәм өстәлләр, чүп савытлары (иң аз дигәндә һәр эскәмия янында берәр), яктырту җайланмалары.

2.11.10.1. Мәйданчыкны плитә белән белән түшәргә киңәш ителә. Ял һәм балалар мәйданчыкларын берләштергәндә балаларның уен зонасында каты түшәмә төрләрен түшәргә рөхсәт ителми.

2.11.10.2. Периметры буйлап яшелләндерергә, берән-сәрән агачлар һәм куаклар, чәчәклекләр утыртырга, вертикаль һәм мобиль яшелләндерү алымнарыннан файдаланырга киңәш ителә. Чирәмлек мәйданчыклары агач һәм куак төркемнәре белән әйләндереп алынырга, тапталуга чыдам үлән төрләре белән түшәлергә тиеш. Әлеге Нормаларның 2.12.7.3 пунктына туры китереп,

ял мәйданчыкларында инсоляция һәм күләгә тәэмин итеlә. Агулы җимеш бирә торган үсемлекләрне кулланырга рөхсәт ителми.

2.11.10.3. Яктырткыч җайланмаларның мәйданчык урнашкан территориясен яктырту режимында эшләве тәэмин итеlә.

2.11.10.4. Өстәл уеннары өчен бер өстәл һәм эскәмияләр урнаштырылган мәйданчыкның минималь зурлыгын 12-15 кв. м чикләрендә билгеләргә киңәш итеlә.

**Спорт мәйданчыклары**

2.11.10. Спорт мәйданчыклары халыкның барлык яшь төркемнәре өчен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен билгеләнгән, аларны торак һәм рекреация билгеләнешендәге территорияләр, спорт корылмалары, гомуми белем бирү мәктәпләре урнашкан урыннар составында проектларга киңәш итеlә. Спорт мәйданчыкларын проектлауны мәйданчыкның махсуслашу төренә карап алып барырга. Мәйданчык чигеннән җиңел автомобильләрне саклау урыннарына кадәрге аралыкны СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200 туры китереп калдырырга.

2.11.11. Гомуми белем бирү мәктәпләре урнашкан территорияләрдә спорт үзәген урнаштыруны һәм проектлауны янәшәдә төзелгән торакларда халыкка хезмәт күрсәтүне исәпкә алып гамәлгә ашырырга. Спорт мәйданчыклары чикләреннән торак йортларның тәрәзәләренә кадәрге аралыкны мәйданчыкларның шау-шу сыйфатламаларыннан чыгып, 20 м башлап 40 м кадәр калдырырга. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен комплекслы (75 балага) физик культура-спорт мәйданчыкларын кимендә 150 кв. м. мәйданда, мәктәп яшендәгеләр өчен (100 балага) кимендә 250 кв. м. мәйданда урнаштырырга.

2.11.12. Спорт мәйданчыгында территорияне төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: түшәмәнең йомшак яки газон төрләре, спорт җайланмалары. Мәйданчыкны яшелләндерергә һәм коймалап алырга киңәш итеlә.

2.11.12.1. Яшелләндерүне мәйданчык периметры буенча мәйданчык кырыеннан кимендә 2 м аралыкта тиз үсә торган агачлар утыртып башкарырга. Ялтыравыклы яфраклары булган, күп күләмдә орлык очырта торган, мул җимеш бирә торган һәм бик иртә яфрак коя торган агачларны һәм куакларны кулланмаска. Мәйданчыкны коймалап алу өчен вертикаль яшелләндерүдән файдаланырга мөмкин.

2.11.12.2. Мәйданчыкларны биеклеге 2,5-3 м, ә спорт мәйданчыклары бер-берсенә тоташкан урыннарда кимендә 1,2 м ятьмәле коймалар белән җиһазларга киңәш итеlә.

**Чүп савытларын урнаштыру мәйданчыклары**

2.11.13. Чүп җыя торган савытлар урнаштыру мәйданчыклары, – каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган урыннар. Мондый мәйданчыкларны булдыру теләсә нинди вазыйфаи билгеләнештәге, каты көнкүреш калдыклары тупланырга мөмкин булган территорияләр һәм урыннар составында күздә тотыла.

2.11.14. Мәйданчыкларны торак биналарның тәрәзәләреннән, балалар

учреждениеләре, ял урыннары чикләреннән кимендә 20 м ераклыкта, тораклар салынган урыннардан – бинага керә торган урыннардан, ерак подъезддан башлап җәүяле юллары буйлап исәпләгәндә, кимендә 100 м аралыкта урнаштырырга кирәк, бу вакытта мәйданчык территориясе юлларга тоташырга, ләкин транспортка йөрергә комачау итмәскә тиеш. Мәйданчыкны (юллардан еракта) аерым урнаштырганда контейнерларны чистарту өчен транспортка җайлы килү юлын һәм борылыш ясау мәйданчыкларын (12 м х 12 м) күздә тотарга кирәк. Мәйданчыкларны транзит транспорт һәм җәяүле коммуникацияләре күренгән зоналардан, биналарның урам фасадларыннан читтә урнаштыруны проектларга киңәш ителә. Мәйданчык территориясен (янәшәдә төзелгән корылмалардан, әвеслекләрдән яки яшел утыртмалардан) күләгәле зонада урнаштырырга киңәш ителә.

2.11.15. Бер контейнерга мәйданчык зурлыгын 2-3 кв.м итеп билгеләргә. Контейнер белән мәйданчык кырые арасындагы юл киңлеген кимендә 1,0 м билгеләргә, контейнерлар арасында – кимендә 0,35 м. Торак билгеләнешендәге территориядә мәйданчыкларны 1 кешегә 0,03 кв. м яки торак йортларда 6-8 подъездга 1 мәйданчык исәбеннән проектларга.

2.11.16. Чүп савытларын урнаштыру мәйданчыгында территорияне төзекләндерү элементларының зарури исемлеге: түшәмәләрнең каты төрләре, мәйданчык өслеген янәшә территорияләр белән тоташтыру урыннары, каты көнкүреш калдыкларын җыю контейнерлары, яктырту җайланмалары. Мәйданчыкны яшелләндерүне проектларга киңәш ителә.

2.11.16.1. Мәйданчык түшәмәсен транспорт йөри торган юл төшәмәсенә аналогик рәвештә түшәргә. Су җыелып торуны һәм контейнер тәгәрәп китүне булдырмас өчен, мәйданчык түшәмәсенең авышлыгын юлга караган өлешендә 5-10% дәрәҗәсендә калдырырга.

2.11.17.2. Мәйданчыкны янәшәдәге юл белән тоташтыру, кагыйдә буларак, бер дәрәҗәдә, борт ташларын җәймичә, газон-бакча борты яки 1,0-1,2 м биеклегендәге декоратив диварчык ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

2.11.17.3. Яктырткыч җайланмаларны кимендә 3 м баганалардан, чиктәш территорияне яктырту режимында эшләтергә киңәш ителә.

2.11.17.4. Яшелләндерүне фитоницид дәрәҗәсе югары булган, куе һәм тыгыз ябалдашлы агачлар ярдәмендә башкарырга киңәш ителә. Мәйданчык түшәмәсеннән ябалдашка кадәрле буш киңлек биеклеген кимендә 3,0 м калдырырга. Мәйданчыкларны визуаль изоляцияләү өчен декоратив диварчыкларны, трельяжларны яки периметры буенча җиләк-җимеше булмаган биек куаклар рәвешендәге тере читтәннәр кулланырга рөхсәт ителә.

**Автокую мәйданчыклары**

2.11.23. Авыл җирлеге территориясендә автокую урыннарының түбәндәге төрләрен күздә тотарга киңәш ителә: автомобильләрне кыска вакыт аралыгында һәм озакка саклау, урам (юл өлешендә тамгаланган парковкалар рәвешендә), урамнан тыш («кесә» һәм юл өлешеннән читкә кереп тора торган урыннар рәвешендә), килгән-киткән транспорт туктала торган (тораклар төзелгән урында), халык автомобилен саклау өчен (микрорайоннар, районнар),

объектлар янәшәсендә (объект яки объектлар төркеме каршысында), башка төрле (йөк машиналарын куя торган, халык яшәгән урыннан аның хәрәкәт итү юнәлешендә автотранспорт юлы буйлап урнашкан һ.б.).

2.11.24. Автокую урыннары чигеннән торакларның һәм иҗтимагый биналарның тәрәзәләренә кадәрге аралыкның СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200 туры китереп билгеләнүен исәпкә алырга кирәк. Объектлар каршында автокую мәйданчыкларында урыннарның бер өлешен СНиП 35-01 туры китереп, инвалидларның автомобильләре өчен проектларга, күләмле бүленеш тамгаларыннан тыш икешәр яки аннан күбрәк урынны блоклап куярга, ачык сары төсендәге тамга белән узып китү чикләрен билгеләргә кирәк.

2.11.25. Автокую мәйданчыкларын пассажир транспорты туктый торган зонада урнаштыруны проектлау рөхсәт ителми, автокую мәйданчыгына керү юлын транспортка күчеп утыру мәйданчыгы азагыннан яки башыннан кимендә 15 м аралыкта карарга.

2.11.26. Автокую мәйданчыкларында территорияне төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: түшәмәләрнең каты төрләре, өслекләрне тоташтыру элементлары, бүленеш тамгалары, яктырта һәм мәгълүмат бирә торган җайланмалар. Автомобильләрне озакка саклау мәйданчыклары әвеслекләр, җиңелчә бокслар, карау эстакадалары белән җиһазландырылырга мөмкин.

2.11.26.1. Мәйданчыкларның түшәмәсен транспорт йөри торган юл төшәмәсенә аналогик рәвештә түшәүне проектларга.

2.11.26.2. Мәйданчык түшәмәсенең юл белән тоташкан урынын борт ташын җәймичә бер дәрәҗәдә, газон белән тоташкан урынын әлеге Кагыйдәләрнең 2.4.3 пунктына туры китереп ясарга.

2.11.26.3. Мәйданчыклардагы бүленеш элементлары тамгалар (ак полосалар), яшелләндерелгән полосалар (газоннар), контейнер яшеллеге рәвешендә ясалырга мөмкин.

2.12. Җәяүле коммуникацияләре.

2.12.1. Җәяүле коммуникацияләре җәяүлеләр өчен юл һәм авыл җирлеге территориясендә хәрәкәт итүне тәэмин итә. Җәяүле коммуникацияләренә түбәндәгеләр кертелә: тротуарлар, аллеялар, кечкенә юллар, сукмаклар. Җәяүле коммуникацияләрен проектлаганда торак пункты территориясендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә киңәш ителә: транспорт коммуникацияләре белән кисешкән урыннарның минималь булуын, җәяүле коммуникацияләренең өзлексезлеген, кешеләргә, инвалидларны һәм халыкның азмобильлекле төркемнәрен дә кертеп, куркынычсыз, каршылыксыз һәм җайлы рәвештә хәрәкәт итү мөмкинлеген. Җәяүле коммуникацияләре системасында төп һәм ярдәмче җәяүле элемтәләрен аерып чыгарырга киңәш ителә.

2.12.2. Җәяүле коммуникацияләрен проектлаганда буйдан-буйга авышлыкны 60%тан артмаган дәрәҗәдә, аркылы авышлыкны (бер кыеклы яки ике кыеклы) оптималь булганда – 20%, минималь булганда – 5%, максималь булганда – 30% дәрәҗәсендә билгеләргә. Инвалид коляскалары белән йөрүне тәэмин итүне исәпкә алып, җәяүле коммуникацияләренең

авышлыгы түбәндәгеләрдән артмаска тиеш: буйдан-буйга – 50%, аркылы – 20%. 30-60% авыш булган җәяүле коммуникацияләрендә һәр 100 м артмаган ешлыкта кимендә 5 м озынлыгындагы яссы урыннар ясарга кирәк. Рельеф шартларына бәйле рәвештә югарыда аталган авышлык дәрәҗәләрен саклау мөмкин булмаса, баскычлар һәм пандуслар урнаштыруны күздә тотарга киңәш ителә.

2.12.3. Тротуарларны киңәйтү зарурлыгы булган очракта, янәшә торучы төзелмәләр составында җәяүле галереяләрен ясарга мөмкин.

**Төп җәяүле коммуникацияләре**

2.12.4. Төп җәяүле коммуникацияләре торак, иҗтимагый, җитештерү һәм башка төрле биналарны җәмәгать транспорты тукталышлары, мәдәни-көнкүреш хезмәтләре күрсәтүче учреждениеләр, рекреация территорияләре белән бәйләнешен, шулай ук иҗтимагый зоналар һәм рекреация объектлары составында төп тартылыш пунктлары арасында бәйләнешне тәэмин итә.

2.12.5. Төп җәяүле коммуникацияләрен трассалау урамнар һәм юллар (тротуарлар) буйлап яки аларга бәйсез рәвештә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Төп җәяүле коммуникацияләренең киңлеген, әлеге Кагыйдәләрнең 3 нче кушымтасына туры китереп, «пик» сәгатьләрендә җәяүлеләрнең хәрәкәт итү тизлегенә һәм бер хәрәкәт полосасының үткәрүчәнлек мөмкинлегенә карап исәпләргә киңәш ителә. Җәяүле коммуникацияләрен трассалауны тартылыш пунктлары арасындагы иң кыска юнәлешләр буенча (рекреация юлларыннан тыш) яки әлеге юнәлешкә карата 30° чамасы почмагында гамәлгә ашырырга киңәш ителә.

2.12.6. Җәяүле коммуникацияләренең транспорт юллары белән кисешкән барлык очракларында да бордюр пандусларын урнаштырырга киңәш ителә. Җәяүле коммуникацияләрендә баскычлар, пандуслар, кечкенә басмалар урнаштырганда әлеге элементларның бердәй үткәрү сәләтен тәэмин итәргә киңәш ителә. Гамәлдәге җәяүле коммуникацияләрен һәм аларга тоташучы газоннарны автотранспорт чараларын туктату һәм кую урыннары буларак файдаланырга рөхсәт ителми.

2.12.7. Төп җәяүле коммуникацияләре буйлап урнашкан утыртмалар, биналар, биналарның чыгып тора торган элементлары һәм техник җайланмалар кечкенә юлларның киңлеген кыскартырга тиеш түгел, шулай ук юл өслегеннән ирекле тирәлекнең минималь биеклеге 2 м тигез булуын күздә тотарга кирәк.

2.12.8. Ныклап төзелмәгән стационар булмаган корылмалар урнаштырылган очракта, җәяүле коммуникацияләренең гомуми киңлеге җәяүле өлеше киңлегеннән, корылманы урнаштыру өчен аерып чыгарыла торган урын киңлегеннән һәм килүчеләр һәм сатып алучылар өчен билгеләнгән буфер зонасы (кимендә 0,75 м) киңлегеннән туплана.

2.12.9. Рекреация басымы бер гектарга 100 кешедән артык тәшкил иткән рекреация объектлары составында төп җәяүле коммуникацияләрен эскәмияләр һәм чүп савытлары урнаштыру мәйданчыклары белән тәэмин итәргә киңәш ителә, соңгылары һәр 100 м артмаган ешлыкта урнаштырыла. Мәйданчык, кагыйдә буларак, җәяүле юлларына тоташып торырга, кимендә 120 см

тирәнлектә булырга тиеш, эскәмия утыргычының тышкы кырыеннан җәяүле юлына кадәрге аралык – кимендә 60 см. Мәйданчык озынлыгын, иң әзе дигәндә, бер эскәмия, ике чүп савыты (чүп өчен кечкенә контейнерлар) урнаштыруга исәпләргә, шулай ук коляскада йөрүче инвалид өчен урыннар (эскәмия белән янәшәдә кимендә 85 см киңлегендә буш урын) калдырырга киңәш ителә.

2.12.10. Төп җәяүле коммуникацияләре территорияләрендә территорияне төзекләндерү элементларының зарури исемлеге: түшәмәләрнең каты төрләре, өслекләрне тоташтыру элементлары, чүп савытлары яки чүп җыю өчен кечкенә контейнерлар, яктырту җайланмалары, эскәмияләр (рекреация территорияләрендә).

2.12.10.1. Төп җәяүле коммуникацияләре түшәмәләренә һәм конструкцияләренә карата таләпләрне аларның сезон әйләнәсе эксплуатацияләнү мөмкинлегеннән чыгып билгеләргә, ә 2,25 м һәм аннан зуррак киңлектә булганда – махсус транспорт чараларының эпизодик килүенә карап. Плитәләр белән түшәүне күздә тотарга киңәш ителә. Нигез күперчекләренең һәм террасаларның югарыгы кырый сызыгында урнашкан җәяүле коммуникацияләренең коймаларын әлеге Кагыйдәләрнең 2.1.7 пунктына туры китереп проектларга.

2.12.10.2. Ныклап төзелмәгән стационар булмаган корылмаларны урнаштырырга мөмкин.

**Ярдәмче җәяүле коммуникацияләре**

2.12.11. Ярдәмче җәяүле коммуникацияләре, кагыйдә буларак, территориядәге урын (мәйданчыклар) чикләрендә төзелмә һәм төзекләндерү элементлары арасында бәйләнеш булдыра, шулай ук рекреация объектлары (сквер, бульвар, парк, урман-парк) территориясендә хәрәкәт итүне тәэмин итә. Ярдәмче җәяүле коммуникацияләренең киңлеге гадәттә 1,0-1,5 м тирәсендә билгеләнә.

2.12.12. Ярдәмче җәяүле коммуникацияләре территориясендә төзекләндерү элементларының зарури исемлеге түшәмәләрнең төрле төрләрен үз эченә ала.

2.12.12.1. Торак пункты скверларындагы, бульварларындагы, бакчаларындагы юлларга тоташу элементлары белән түшәмәнең каты төрләрен карарга киңәш ителә. Плитәләр белән ныгытырга киңәш ителә.

2.12.12.2. Эре рекреация объектларындагы (парклар, урман-парклар) юлларга йомшак яки катнаш төрдәге түшәмәләрне түшәргә, җәяүле сукмакларын табигый грунт түшәмәсеннән ясарга киңәш ителә.

2.13. Транспорт үтү юллары.

2.13.1. Транспорт үтү юллары – биналар һәм кварталлар территорияләре эчендәге урыннар, эре рекреация объектлары, җитештерү һәм иҗтимагый зоаналар белән ике арада транспорт бәйләнешен, шулай ук торак пунктындагы урам-юл челтәре белән бәйләнеш тәэмин итә торган транспорт коммуникацияләре системасы элементлары.

2.13.2. Транспорт үтү юлларын проектлауны СНиП 2.05.02 исәпкә алып

башкарырга. Транспорт үтү юлларын проектлаганда янәшә территорияләрнең ландшафтын һәм экологик торышын саклауны яки яхшыртуны тәэмин итәргә кирәк.

2.13.3. Велосипедта йөрү юлларын комплекслы төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: түшәмәнең каты төре, велосипед юлының янәшә территорияләргә тоташу элементлары.

2.13.3.1. Урамнар һәм юллар буйлап урнаштырыла торган велосипед юлларында яктыртуны тәэмин итәргә кирәк, ә рекреация территорияләрендә – велосипед юллары буйлап яшелләндерергә.

2.13.3.2. Юллар буйлап утыртылган утыртмалар юл габаритларын кыскартырга тиеш түгел, юл өслегеннән ирекле тирәлек биеклеге кимендә 2,5 м тәшкил итәргә тиеш. Эре рекреацияләр составында велосипед юллары трассаларында техник хезмәт күрсәтү пунктын урнаштырырга киңәш ителә.

## 3 БҮЛЕК.
## ИҖТИМАГЫЙ БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

3.1. Гомуми нигезләмәләр.

3.1.1. Иҗтимагый билгеләнештәге территорияләрдә төзекләндерүне нормага салу объектлары булып түбәндәгеләр тора: торак пунктындагы иҗтимагый тирәлекләр, иҗтимагый төзелмә урыннары һәм зоналары, алар төрле бәйләнешләрдә авыл җирлегендә иҗтимагый территорияләрнең барлык төрләрен формалаштыра: авыл җирлегенең торак пункты үзәге, күпфункцияле, магистраль буе һәм махсуслаштырылган иҗтимагый зоналары.

3.1.2. Төзекләндергәндә иҗтимагый билгеләнеш территорияләрендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә: визуаль кабул итү өчен территорияләрнең ачык һәм үткәрүчән булуын (каты коймалар булмавын), халыкка каршылыксыз хәрәкәт итү шартларын (азмобильлекле төркемнәрне дә кертеп), тарихи барлыкка килгән планлаштыру структурасын һәм төзелмә масштабын саклап тоту алымнарының, торак пунктындагы әйләнә-тирә мохит белән төзекләндерү элементларының стиль буенча бердәмлегенә ирешүне.

3.2. Иҗтимагый тирәлекләр.

3.2.1. Авыл җирлегендәге иҗтимагый тирәлекләр җәяүле коммуникацияләрен, җәяүле зоналарын, кешеләр актив килә торган иҗтимагый төзелмә урыннарын, торак пункты составында урнашкан яшелләндерү урыннарын, магистраль буе һәм күпфункцияле зоналарны, торак пунктлары үзәкләрен үз эченә ала.

3.2.1.1. Җәяүле коммуникацияләре һәм җәяүле зоналары җәяүлеләргә юл һәм торак пункты территориясе буенча хәрәкәт итүне тәэмин итә (әлеге Кагыйдәләрнең 2.13, 7.2 һәм 7.3 пунктлары).

3.2.1.2. Кешеләр актив йөри торган режимлы иҗтимагый төзелмә объектлары – болар сәүдә, мәдәният, сәнгать, мәгариф һ.б. учреждениеләр, җирле әһәмияттәге объектлар; алар объект территориясе каршында аерып

чыгарып, яисә аннан башка гына оештырылырга мөмкин, бу очракта әлеге урын чикләрендә төзелгән биналарның һәм корылмаларның тышкы аскы контуры белән туры килерлек итеп билгеләнә.

3.2.1.3. Авыл җирлегендә иҗтимагый тирәлек территорияләрендә яшелләндерү урыннары чәчәклекләр, газоннар, берән-сәрән, төркем-төркем, рәт-рәт утыртмалар, яшелләндерүнең вертикаль, күп ярусллы, мобиль формалары рәвешендә проектлана.

3.2.2. Авыл җирлегендә иҗтимагый тирәлек территориясендә төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: плитә белән ныкландырылган рәвештәге каты түшәмә төрләре, өслекләрне тоташтыру элементлары, яшелләндерү, эскәмияләр, чүп савытлары һәм чүп өчен кечкенә контейнерлар, урамдагы техник җайланмалар, яктырту җайланмалары, архитектура-декоратив яктырту җайланмалары, мәгълүмат күрсәткечләре, яшелләндерү урыннарын яклау элементлары (металл коймалар, түшәмәләрнең махсус төрләре һ.б.).

3.2.2.1. Иҗтимагый тирәлекләр территориясендә декоратив-кулланма сәнгать әсәрләрен, декоратив су җайланмаларын урнаштырырга киңәш ителә.

3.2.2.2. Җәяүле зоналары һәм коммуникацияләре территорияләрендә тышкы реклама, ныклап төзелмәгән стационар булмаган ваклап сәүдә итү, көнкүреш хезмәтләре күрсәтү һәм туклану корылмаларын урнаштырырга мөмкин.

3.2.2.3. Иҗтимагый төзелмәләр урнашкан территориядә (объект территорияләре булганда) коймалар һәм тышкы реклама чараларын урнаштырырга мөмкин.

3.3. Иҗтимагый төзелмә урыннары һәм махсуслаштырылган зоналар.

3.3.1. Иҗтимагый төзелмә урыннары (әлеге Кагыйдәләрнең 3.2.1.2 пунктында каралганнардан тыш) – ул килү чикләнгән яки ябык булган режимдагы иҗтимагый учреждение җирләре: хакимият органнары һәм идарәләр, хастаханәләр һәм шуңа охшаш объектлар. Алар объект янәшәсендәге территорияне аерып алып та, аннан башка да оештырылырга мөмкин, бу очракта әлеге урын чикләрен төзелгән биналарның һәм корылмаларның тышкы аскы контуры белән туры килә торган итеп билгеләргә кирәк.

3.3.1.1. Иҗтимагый төзелмә урыннарын һәм андагы махсуслаштырылган зоналарны төзекләндерүне проект биремenә һәм тармак билгеләнешенә туры китереп проектларга.

3.3.2. Иҗтимагый төзелмә урыннарында (объект каршында территорияләр булганда) һәм иҗтимагый төзелмәләрнең махсуслаштырылган зоналары территорияләрендә территорияне төзекләндерү элементларының зарури исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала: түшәмәләрнең каты төрләре, өслекләрне тоташтыру элементлары, яшелләндерү, чүп савытлары яки чүп җыю өчен кечкенә контейнерлар, яктырту җайланмалары, учреждениеләрнең мәгълүмат күрсәткечләре. Килгән кешеләрне кабул итүгә бәйле билгеләнештәге учреждениеләр өчен зарури рәвештә эскәмияләр урнаштыруны күздә тотарга.

3.3.2.1. Коймалар, тышкы реклама чараларын урнаштырырга мөмкин.

# 4 БҮЛЕК.
# ТОРАК БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

4.1. Гомуми нигезләмәләр.

4.1.1. Торак билгеләнешендәге территорияләрдә төзекләндерүне нормага салу объектлары булып түбәндәгеләр тора: иҗтимагый тирәлекләр, тораклар урнашкан, балалар бакчалары, мәктәпләр төзелгән, автотранспорт чараларын даими һәм вакытлыча саклау урыннары, алар төрле бәйләнешләрдә торак төркемнәр, микрорайоннар, торак районнар формалаштыра.

4.2. Иҗтимагый тирәлекләр.

4.2.1. Торак билгеләнешендәге территорияләрдә иҗтимагый тирәлекләр җәяүле коммуникацияләре, торак төркемнәренә, микрорайоннарга, торак районнарга хезмәт күрсәтүче учреждениеләр урнашкан урыннар һәм уртак файдаланудагы яшел территорияләр системасыннан формалаша.

4.2.2. Торак төркемнәренә, микрорайоннарга, торак районнарга хезмәт күрсәтүче учреждениеләр аларга кирә торган урыннарда мәйданчыклар белән җиһазлана. Килүчеләр саны күп булган хезмәт күрсәтүче учреждениеләр (кибетләр, базарлар, поликлиникалар) өчен объектлар янында автокую урыннары коруны күздә тотарга.

4.2.3. Җәяүле коммуникацияләре территориясендә һәм хезмәт күрсәтүче учреждениеләр урнашкан урында төзекләндерү элементларының зарури исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала: түшәмәләрнең каты төрләре, үсемлекләрне тоташтыру элементлары, чүп савытлары, чүп җыю өчен кечкенә контейнерлар, яктырту җайланмалары, мәгълүмат күрсәткечләр.

4.2.3.1. Плитәләр белән ныкландырылган рәвештә каты түшәмә төрләрен, шулай ук мобиль яшелләндерүне, урамдагы техник җайланмалар, эскәмияләр урнаштыруны күздә тотарга киңәш ителә.

4.2.3.2. Тышкы реклама чараларын, ныклап төзелмәгән стационар булмаган корылмаларны урнаштырырга мөмкин.

4.2.4. Уртак файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләрне торак төркемнәрен, микрорайоннарны, торак районнарны яшелләндерүнең бердәм системасы рәвешендә формалаштырырга кирәк. Яшелләндерү системасы җәяүле һәм транспорт коммуникацияләре (газоннар, рәтләп утыртылган агачлар һәм куаклыклар) буйлап утыртылган яшел утыртма җирләрен, торак төзелгән урыннардан читтәге яшелләндерелгән мәйданчыкларны (спорт, спорт-уен, этләр йөртү урыны һ.б.), рекреация объектларын (скверлар, бульварлар, бакчалар) үз эченә ала.

4.3. Тораклар төзелгән урыннар.

4.3.1. Торак төзелгән урыннарны төзекләндерүне йорт яны территориясеннән күмәк яки аерым куллану холкын исәпкә алып проектларга.

4.3.2. Торак төзелгән урын территориясендә йорт яны территориясе күмәк файдаланганда (күпфатирлы төзелеш) түбәндәгеләрне күздә тотарга: транспорт

үтү юлын (транспорт үтү юлларын), җәяүле коммуникацияләрен (төп, ярдәмче), мәйданчыкларны (мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен уен, өлкәннәр өчен ял мәйданчыклары, чүп җыю савытларын урнаштыру урыннары, килүче-китүче транспортларны туктату урыннары, керү төркемнәре каршындагы мәйданчыклар), яшелләндерелгән территорияләрне. Әгәр әлеге урын территориясенең күләме мөмкин итсә, әлеге урын чикләрендә спорт мәйданчыкларын һәм мәктәп яшендәге балалар өчен уен мәйданчыкларын, этләрне йөртү мәйданчыкларын урнаштырырга рөхсәт ителә.

4.3.3. Күмәк файдаланудагы торак төзелгән урын территориясендә төзекләндерү элементларының зарури исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала: транспорт үтү юлларының каты түшәмә төрләрен, мәйданчыкларның төрле түшәмә төрләрен (әлеге Кагыйдәләрнең 2.12 бүлекчәсе), өслекләрне тоташтыру элементларын, мәйданчыкларның җиһазланышын, яктырту җайланмаларын.

4.3.3.1. Тораклар урнашкан урынны яшелләндерүне торак йортның нигез күперчеге белән транспорт үтә торган юл арасында (йорт яны яшеллек полосалары), транспорт үтү юлы белән әлеге урынның тышкы чикләре арасында формалаштырырга: йорт яны полосаларында – чәчәклекләр, газоннар, үрелеп үсә торган үсемлекләр, куаклыкларның җыйнак төркемнәре, биек булмаган аерым торучы агачлар; әлеге урынның калган территориясендә – яшелләндерүнең ирекле композицияләре һәм төрле алымнары.

4.3.3.2. Тораклар төзелгән урынны коймалап алырга мөмкин, әгәр ул урамнар буйлап тораклар төзелгән урыннарның урнашу шартларына каршы килмәсә.

4.3.3.4. Тораклар төзелгән урыннарда реконструкцияләнә торган территорияләрдә авыру һәм зәгыйфь агачларны алып атуны, сәламәт агачларны яклауны һәм декоратив бизәүне, планлаштырылмаган төзелмәләрне (складларны, сарайларны, стихияле барлыкка килгән гаражларны, шул исәптән «Ракушка» тибындагыларын) юкка чыгаруны күздә тотарга, төзекләндерүнең әхлакый һәм физик яктан искергән элементларын алмаштырырга киңәш ителә.

4.5. Автотранспорт чараларын озакка һәм кыска вакытка саклау урыннары.

4.5.1. Автотранспорт чараларын озакка һәм кыска вакытка саклау урыннарында түбәндәгеләрне күздә тотарга: гаражлар яки тукталышлар, мәйданчыклар (туплый торган), керү һәм чыгу юллары, җәяүле юллары корырга. Автотранспорт чараларын озакка һәм кыска вакытка саклау урыннарына килә торган юлларны җәяүле юлларының төп юнәлешләре белән кисешми торган итеп урнаштырырга. Автотранспорт чараларын озакка һәм кыска вакытка саклау урыннары аша узучы транзит җәяүле юллары оештырылуына юл куймаска. Автотранспорт чараларын озакка һәм кыска вакытка саклау урынын калган территориядән кимендә 3 м киңлегендәге яшел утыртмалар полосасы белән изоляцияләргә. Керү һәм чыгу юлларында тротуарларның һәм газоннарның бортлары, кагыйдә буларак, кимендә 8 м радиуслы итеп түгәрәкләнеп торырга тиеш.

4.5.2. Автотранспорт чараларын озакка һәм кыска вакытка саклау урынында төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: түшәмәләрнең каты төрләре, өслекләрне тоташтыру элементлары, коймалар, чүп савытлары яки чүп җыю өчен кечкенә контейнерлар, яктырту җайланмалары, мәгълүмат җайланмалары (күрсәткечләр).

4.5.2.1. Җәяүле юлларында юл өслегенә төшү урынын – бордюрлы пандус (бер урынга кимендә берне) карарга кирәк.

4.5.2.2. Әлеге урын чикләре буйлап фитонцидлык дәрәҗәсе югары булган биек үсә торган куе куаклык һәм агач утыртмаларын формалаштырырга кирәк.

4.5.3. Автотранспорт чараларын озакка һәм кыска вакытка саклау өчен туры һәм аз күләмдә авышлыклы түбәле, күпкатлы торак һәм иҗтимагый төзелмәдә урнаштырылган корылмаларның түбәләрен яшелләндерү каралырга мөмкин. Түбәне яшелләндергәндә чәчәкләр белән бизәү киңәш ителә, аның мәйданы түбәне яшелләндерү мәйданының кимендә 10%ын тәшкил итәргә тиеш, шулай ук яссы тамыр системалы агачлар һәм куаклыклар утырту киңәш ителә.

4.5.4. Ныклап төзелмәгән стационар булмаган гараж корылмаларында автомобиль саклау өчен билгеләнгән территория урыннарын юлларны һәм транспорт үтү юлларын каты түшәмә төрләре белән җиһазлап, яктырту җайланмалары белән төзекләндерергә. Гараж корылмаларын яки бүлемтекләрен, яшелләндерү элементлары белән һәм коймалар урнаштырып, унификацияле итеп күздә тотарга.

## 5 БҮЛЕК.
## РЕКРЕАЦИЯ БИЛГЕЛӘНЕШЕНДӘГЕ ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

5.1. Гомуми нигезләмәләр.

5.1.1. Рекреация билгеләнешендәге территорияләрдә төзекләндерүне нормага салу объектлары булып рекреация объектлары тора – махсус сакланучы табигый территория зоналарындагы территорияләрнең бер өлеше: ял зоналары, парклар, бакчалар, бульварлар, скверлар. Рекреация объектларын төзекләндерүне проектлау әлеге территория өчен билгеләнгән хуҗалык эшчәнлеге режимнарына туры китереп башкарылырга тиеш.

5.1.2. Бакча-парк сәнгате, тарих һәм архитектура һәйкәлләрен төзекләндерү аларның тарихи йөзен реконструкцияләүне яки реставрацияләүне, планлаштыруны, яшелләндерүне үз эченә ала, үсемлекләр ассортиментын булдыруны да кертеп. Парк территориясен төзекләндерү элементлары белән җиһазлауны һәм тәэмин итүне ул урнашкан территориянең тарихи-мәдәни регламентына (булган очракта) туры китереп проектларга киңәш ителә.

5.1.3. Рекреация объектларын планлаштыру структурасы территориянең шәһәр төзелеше, вазыйфаи һәм табигый үсенчәлекләренә туры килергә тиеш. Төзекләндерүне проектлаганда табигатьне саклау факторларына өстенлек бирергә: эре рекреация объектлары өчен – ландшафтның табигый, гадәти

холкын бозмаска; кече рекреация объектлары өчен (скверлар, бульварлар, бакчалар) – утыртмаларны актив тәрбияләп торырга; барлык төр рекреация объектлары өчен – торак пунктындагы югары техноген һәм рекреация басымнарыннан сакларга.

5.1.4. Рекреация объектларын реконструкцияләгәндә түбәндәгеләрне күздә тотарга:

– урман-парклар өчен: тотрыклы вазыйфалау сәләтенә ия экосистемалар булдыру, ландшафтларның һәм утыртмаларның кыйммәтенә карап, чик дәрәҗәдәге рекреация басымын, файдалану режимнарын билгеләп, территорияне вазыйфаи зоаналарга бүлү һәм урман-паркның төрле зоналары өчен төзекләндерү чараларын уздыру;

– парклар һәм бакчалар өчен: планлаштыру структурасын реконструкцияләү (мисал өчен, юл-сукмак челтәре тыгызлыгын үзгәртү), утыртмалар тыгызлыгы арткан урыннарны сирәкләү, авыру, карт, декоратив булмаган агачларны һәм азкыйммәтле төрләргә караган үсемлекләрне алып ату, аларны декоратив-яфраклы һәм матур чәчәк атучы агач һәм куаклык формалары белән алмаштыру, ял мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары оештыру;

– скверлар өчен: катлаулы вертикаль структуралы төркемнәр һәм чәчәк түтәлләре формалаштыру, авыру, карт һәм декоратив булмаган агачларны кисәргә, юл кырые белән иң якында урнашкан агачлар рәте белән ике арада аралык булдырырга һәм аны арттырырга, куркыныч зонасыннан читтә махсус утырту һәм карап тоту технологияләрен кулланып, барыннан бигрәк, зур агачлар утыртырга.

5.1.5. Рекреация билгеләнешендәге территорияләрдә инженер коммуникацияләрен проектлауны территориянең экологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, башлыча җир асты тонельләрендә яки рекреация объектын уратып башкарырга.

5.2. Ял зоналары.

5.2.1. Ял зоналары – актив массакүләм ял итү, су коену һәм рекреация оештыру өчен билгеләнгән һәм җиһазландырылган территорияләр.

5.2.2. Сулыкларның яр буе өлешендә ял зоналарын проектлаганда комлыкның мәйданы һәм комлыкның яр буе линияләренең озынлыгы килүчеләр санын исәпләп билгеләнә.

5.2.3. Ял зонасы территориясендә түбәндәгеләрне урнаштырырга киңәш ителә: килү юлы белән медицина хезмәтләре күрсәтү пунктын, коткару станциясен, җәяүле юлларын, инженер җайланмаларын (эчә торган су белән тәэмин итү һәм су агызу, җир өслегендәге пычранган агынтының сулыкка эләгүеннән саклау). Медицина пунктын коткару станциясе белән янәшә урнаштыралар һәм «Медпункт» язуы белән яки ак фонда кызыл тәре сурәте белән, шулай ук – ашыгыч ярдәм машинасына каршылыксыз үтеп керү өчен санитар транспортны парковкалау урыны белән җиһазлыйлар. Медпункт бинасы кимендә 12 кв. м. мәйданда урнаштырыла, ул табигый һәм ясалма яктыртыла, аның сууткәргече һәм бәдрәфе була.

5.2.4. Ял зонасы территориясендә төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: килү юлының каты түшәмә төрләре, катнаш – юллар (плитә, газонга батырылган), яшелләндерү, эчә торган фонтанчыклар, эскәмияләр, чүп савытлары, чүп өчен кече контейнерлар, комлык җайланмалары (кояштан әвеслекләр, ятаклар, чишенеп-киенү өчен кабинкалар), бәдрәф кабиналары.

5.2.4.1. Яшелләндерүне проектлаганда түбәндәгеләрне тәэмин итәргә киңәш ителә:

– ял зонасы мәйданының кимендә 80%ыннан ким булмаган күләмдә үлән катламын, агач-куакларны һәм яр буе үсемлекләрен сакларга;

– сулык ярларын яшелләндерергә һәм формалаштырырга (убылуга һәм җимерелүгә дучар булган сөзәк урыннарда яр ныгыту поясы, текә тау битләрендә су тота торган пояслар – төп дренаж һ.б.);

– ял зонасы территориясеннән башка максатларда (этләрне йөртү, уен шәһәрләре, аттракционнар һ.б. кору өчен) файдалануга юл куймаска.

5.2.4.2. Койма, урамдагы техник җайланмаларны («су», «туңдырма» сәүдә арбалары) урнаштырырга мөмкин.

5.3. Парклар.

5.3.1. Авыл җирлеге территориясендә торак районнары парклары проектлана.

5.3.2. Торак район паркы гадәттә торак район халкының актив һәм тыныч ялын оештыру өчен билгеләнә. Парк территориясендә түбәндәгеләрне карарга кирәк: аллеялар һәм юллар системасын, мәйданчыклар (балалар, тыныч һәм актив ял, спорт). Парк территориясе янында яки аның составында торак районның спорт комплексы, балалар өчен спорт-уен комплекслары, роликларда йөрү урыннары урнашырга мөмкин.

5.3.3. Торак район паркы территориясендә төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: төп юлларда түшәмәләрнең каты төрләре, өслекләрне тоташтыру элементлары, яшелләндерү, эскәмияләр, чүп савытлары һәм чүп өчен кече контейнерлар, мәйданчыкларга җиһазланышлар, яктырту җайланмалары.

5.3.4. Торак район паркын яшелләндергәндә уртача салкын Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш климат зоналары өчен сыйфатлы булган үсемлек төрләреннән файдаланып, чәчәкләр белән бизәүне күздә тотарга киңәш ителә.

5.3.5. Парк территориясен коймалап алырга, урамдагы техник җайланмаларны («су», «туңдырма» сатучы арбаларны) һәм ныклап төзелмәгән стационар булмаган туклану корылмаларын (җәйге кафеларны) урнаштырырга мөмкин.

5.4. Бакчалар.

5.4.1. Торак пункты территориясендә бакчаларның түбәндәге төрләрен формалаштырырга киңәш ителә: ял һәм җәяүләп йөрү бакчалары, корылмалар каршындагы бакчалар, түбәләрдәге бакчалар һ.б.

**Ял һәм җәяүләп йөрү бакчалары**

5.4.2. Ял һәм җәяүләп йөрү бакчалары гадәттә халыкның кыска вакытлы

ялын оештыру өчен билгеләнгән. Бакча территориясе буйлап транзит җәяүле хәрәкәте рөхсәт ителә.

5.4.3. Кагыйдә буларак, ял һәм җәяүләп йөрү бакчалары территориясендә төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: плитә белән ныкландырылган рәвештә юл түшәмәләренең каты төрләре, өслекләрне тоташтыру элементлары, яшелләндерү, эскәмияләр, чүп савытлары, урамдагы техник җайланмалар («су», «туңдырма» арбалары), яктырту җайланмалары.

5.4.3.1. Капламаның төрле төсләр белән бирелешен куллануны, су җайланмаларын, декоратив-кулланма бизәү элементларын, архитектура-декоратив яктырту җайланмаларын урнаштыруны, яшелләндерүне пейзаж холкында формалаштыруны күздә тотарга киңәш ителә.

5.4.3.2. Койма, ныклап төзелмәгән стационар булмаган туклану корылмаларын (җәйге кафе) урнаштыруны күздә тотарга мөмкин.

**Биналар һәм корылмалар каршындагы бакчалар**

5.4.4. Биналар һәм корылмалар каршындагы бакчалар гадәттә иҗтимагый оешма биналары, тамаша учреждениеләре һәм иҗтимагый билгеләнештәге башка төрле биналар һәм корылмалар каршысында формалаша. Бакчаның планлаштыру структурасы, кагыйдә буларак, объектка карата рациональ якын килүне һәм килгән кешеләрне тиз арада эвакуацияләүне тәэмин итәргә тиеш.

5.4.5. Бакчаны төзекләндерү элементларының зарури, киңәш ителә һәм рөхсәт ителә торган исемлеген әлеге Кагыйдәләрнең 5.4.3 пунктына туры китереп кабул итәргә киңәш ителә. Яшелләндерү һәм чәчәкләр белән бизәү алымнарын биналарның һәм корылмаларның вазыйфаи билгеләнешенә карап кулланырга киңәш ителә: партерлы (репрезентатив, парад бакча), интерьерлы – ял мәйданчыклары, ян декорацияләр, чатырлар, ландшафт чәчәклекләре белән (тамаша учреждениеләре каршындагы бакча).

5.5. Скверлар.

5.5.1. Скверлар гадәттә кыска вакыт аралыгында ял итү, йөреп керү, транзит җәяүле хәрәкәте өчен билгеләнә.

5.5.2. Сквер территориясендә төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: юлларның һәм мәйданчыкларның каты түшәмәле төрләре, өслекләрне тоташтыру элементлары, яшелләндерү, эскәмияләр, чүп савытлары яки чүп өчен кечкенә контейнерлар, яктырту җайланмалары, архитектура-декоратив яктырту җайланмалары.

5.5.2.1. Юлларның өслеген өстенлекле рәвештә плитә белән тышлау рәвешендә проектларга, түшәмәне төрле төсләр белән бирү чишелешен күздә тотарга, декоратив-кулланма бизәкләү элементларын, тәбәнәк декоратив коймалар урнаштырырга киңәш ителә.

## 6 БҮЛЕК.
## СӘНӘГЫЙ БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

6.1. Гомуми нигезләмәләр.

6.1.1. Сәнәгый билгеләнештәге территорияләрдә төзекләндерүне проектлауга карата таләпләр ведомство нормативларында билгеләнә. Сәнәгый билгеләнеш территорияләрендә төзекләндерүне нормага салу объектлары булып, кагыйдә буларак, сәнәгый төзелмә зоналарындагы иҗтимагый тирәлекләр һәм санитар-саклык зоналарының яшелләндерелгән зоналары тора.

6.2. Яшелләндерелгән санитар-саклык зоналары территорияләре.

6.2.1. Сәнәгый билгеләнеш территорияләренең санитар-саклык зоналарын (ССЗ) яшелләндерү мәйданы СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200 таләпләренә туры китереп, проект карарында билгеләнергә тиеш.

6.2.2. Кагыйдә буларак, ССЗ яшелләндерелгән территорияләрен төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: чиктәш территорияләр белән яшелләндерелгән урынның тоташу элементлары (борт ташы, терәк диварчыклар һ.б.), утыртмаларны һәм яшелләндерү урыннарын саклау элементлары.

6.2.2.1. Яшелләндерүне бертөрлелек һәм бөртонлылыкны чикли торган сәнгатьле композицияләр рәвешендә формалаштырырга киңәш ителә.

## 7 БҮЛЕК.
## ТРАНСПОРТ ҺӘМ ИНЖЕНЕР КОММУНИКАЦИЯЛӘРЕ ТЕРРИТОРИЯЛӘРЕНДӘ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ОБЪЕКТЛАРЫ

7.1. Гомуми нигезләмәләр.

7.1.1. Торак пунктының транспорт коммуникацияләре территорияләрендә төзекләндерүне нормага салу объектлары булып кызыл линияләр чикләрендә торак пунктының урам-юл челтәре (УЮЧ), төрле типлардагы җәяүле кичүләре тора. Төзекләндерүне билгеле бер категориягә караган урамнар челтәренә, аерым урамга яки мәйданга, урамның яки мәйданның бер өлешенә, транспорт корылмасына проектларга мөмкин.

7.1.2. Инженер коммуникацияләре территорияләрендә төзекләндерүне нормага салу объектлары булып магистраль челтәрләрнең, инженер коммуникацияләрнең сак-эксплуатация зоналары тора.

7.1.3. Транспорт һәм инженер коммуникацияләре территорияләрендә комплекслы төзекләндерүне СНиП 35-01, СНиП 2.05.02, ГОСТ Р 52289, ГОСТ Р 52290-2004, ГОСТ Р 51256 исәпкә алып, халыкка куркынычсызлык шартларын тудырып һәм чиктәш территорияләрне транспорт һәм инженер коммуникацияләре йогынтысыннан саклауны тәэмин итеп проектларга кирәк.

7.2. Урамнар һәм юллар.

7.2.1. Торак пункты территориясендә урамнар һәм юллар билгеләнеше һәм транспорт сыйфатламалары буенча район әһәмиятендәге магистраль

урамнарга, җирле әһәмияттәге урамнарга һәм юлларга бүленә.

7.2.2. Урамнар һәм юллар территориясендә төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: юл өслегенең һәм тротуарларның каты түшәмә төрләре, өслекләрне тоташтыру элементлары, урамнар һәм юллар буйлап яшелләндерү, куркыныч урыннарны коймалау, яктырту җайланмалары, юл хәрәкәте буенча мәгълүмат күрсәткечләре (юл билгеләре, тамгалар, светофор җайланмалары).

7.2.2.1. Юл өслегенең төрләре һәм реконструкциясе урамның категориясен исәпкә алып һәм куркынычсыз хәрәкәт итүне тәэмин итеп проектлана. Урамнарның һәм юлларның түшәмәләре өчен киңәш ителә торган материаллар әлеге Кагыйдәләрнең 7 нче кушымтасында китерелде.

7.2.2.2. Урамнарны һәм юлларны яшелләндерүне проектлау өчен утыртмалардан җир асты коммуникацияләре челтәрләре һәм урам-юл челтәренең башка корылмаларына кадәр, СНиПамнарга туры китереп, минималь аралык билгеләнә. Агачларны түшәмәгә урнаштырырга мөмкин. Борылышларда һәм тукталышларда яшел утыртмалар урнаштыруны көйләнми торган хәрәкәт булганда әлеге Кагыйдәләрнең 7.4.2 пунктына туры китереп проектларга киңәш ителә. Юлның кырый өлеше белән иң якындагы агачлар рәте арасында буфер зонасын арттыруны күздә тотарга киңәш ителә. Куркыныч зона чикләреннән читтә мондый объектлар өчен махсус үстерелә торган үсентеләрне (әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтаның 16 нчы таблицасы) утыртырга киңәш ителә.

7.2.2.3. Транспорт коммуникацияләре территориясендәге коймалар, гадәттә, транспорт чараларының һәм җәяүлеләрнең имин хәрәкәт итүен оештыру өчен билгеләнә. Урам-юл челтәре коймаларын һәм ясалма корылмаларны (эстакадалар, юлүткәргечләр, күперләр һ.б.) ГОСТ Р 52289, ГОСТ 26804 туры китереп проектларга кирәк.

7.3. Мәйданнар.

7.3.1. Вазыйфаи билгеләнеше буенча мәйданнар түбәндәгеләргә бүленә: төп (хакимият органнары биналары, иҗтимагый оешмалар каршында), объект янындагы (һәйкәлләр, кинотеатрлар, музейлар, стадионнар, парклар, базарлар һ.б. каршында), иҗтимагый-транспорт (вокзаллар янында), мемориал (истәлекле объектлар яки урыннар янында), транспортлар борылыш ясый торган мәйданнар. Төзекләндерүне проектлаганда җәяүле һәм транспорт хәрәкәтен, төп һәм җирле транспорт агымнарын максималь мөмкин булганча бүлүне тәэмин итәргә киңәш ителә.

7.3.2. Мәйдан территорияләренә түбәндәгеләр керә: юл өлеше, җәяүле өлеше, яшелләндерү урыннары һәм территорияләре.

7.3.3. Мәйдан территориясендә төзекләндерү элементларының зарури исемлеген әлеге Кагыйдәләрнең 7.2.2 пунктына туры китереп кабул итәргә. Вазыйфаи билгеләнешенә карап, мәйданнарны төзекләндерүнең өстәмә элементларын урнаштырырга киңәш ителә:

– төп, объект янәшәсендәге, мемориал мәйданнарда – монументаль-декоратив сәнгать әсәрләрен, су җайланмаларын (фонтаннарны);

– иҗтимагый-транспорт мәйданнарында – тукталыш павильоннарын, ныклап төзелмәгән стационар булмаган ваклап сәүдә итү, туклану, көнкүреш хезмәтләре күрсәтү корылмаларын, тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын.

7.3.3.1. Мәйданның җәяүле өлешендәге түшәмә төрләре махсус билгеләнештәге автомобильләр (янгын сүндерү, авария, җыештыру һ.б.) үтү, җиңел автомобильләрне вакытлыча туктап тору мөмкинлеген күздә тотарга тиеш.

7.3.3.2. Мәйданның җәяүлеләр өлешендә автомобильләр үтәргә һәм вакытлыча туктап торырга мөмкин булган урыннарны төс белән яки түшәмә фактурасы белән, мобиль яшеллек (контейнерлар, гөл чүлмәкләре), күчмә коймалар белән аерырга киңәш ителә.

7.3.3.3. Мәйданны яшелләндергәндә периметры буенча яшелләндерергә, утыртмаларны мәйдан үзәгендә урнаштырырга (сквер яки куркынычсызлык утравы), шулай ук әлеге алымнарны берләштерергә киңәш ителә. Торак пунктының тарихи тирәлеге яки барлыкка килгән төзелеш шартларында җыйнак һәм (яки) мобиль яшелләндерү алымнарын кулланырга киңәш ителә. Мәйдан үзәгендә куркынычсызлык утравын яшелләндерүне партер яшелләндерү яки биек агачлар рәвешендә әлеге Кагыйдәләрнең 7.4.2 пунктына туры китереп, машина йөртүчеләр өчен кирәкле күренү почмагын исәпкә алып гамәлгә ашырырга киңәш ителә.

7.4. Җәяүле кичүләре.

7.4.1. Җәяүле кичүләрен урамнар һәм юллар белән төп җәяүле коммуникацияләре кисешкән урыннарда урнаштырырга киңәш ителә. Җәяүле кичүләре урамның юл өлеше белән бер дәрәҗәдә (җир өстендә) проектлана.

7.4.2. Көйләнми торган хәрәкәт урамнарында җир өстендә җәяүле кичүләрен урнаштырганда күренү очпочмагын тәэмин итәргә киңәш ителә, аның зонасында төзелмәләр, ныклап төзелмәгән стационар булмаган корылмалар, реклама такталары урнаштырмаска, 0,5 м биегрәк яшел утыртмалар утыртмаска кирәк. Өчпочмак якларын түбәндәгечә кабул итәргә киңәш ителә: транспортка рөхсәт ителгән хәрәкәт тизлеге сәгатенә 40 чм булганда – 8x40 м; сәгатенә 60 чм булганда – 10x50 м.

7.4.3. Җир өстендә җәяүле кичүләрен төзекләндерү элементларының зарури исемлегенә түбәндәгеләр керә: юл тамгасы, тротуар өслегеннән юл өслегенә төшү өчен пандуслар, яктырту җайланмалары.

7.5. Транспорт, инженер коммуникацияләренең техник зоналары, су саклау зоналары.

7.5.1. Торак пункты территориясендә шәһәр төзелешен җайга салу линияләре белән бүленә торган техник (сак-эксплуатация) зоналарның түбәндәге төрләрен күздә тоталар: магистраль коллекторлар һәм трубаүткәргечләр, югары һәм түбән көчәнешле кабельләр, аз токлы кабельләр, югары вольт тапшыру линияләре.

7.5.2. Магистраль трубаүткәргечләрнең, югары, түбән көчәнешле һәм аз токлы кабельләрнең, югары вольт тапшыру линияләренең аерып чыгарылган техник (сак) зоналары территориясендә каты түшәмә төрләре белән транспорт-

җәяүле коммуникацияләрен салу, яктырткыч җайланмалар, тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру, мәйданчыклар (балалар, ял, автомобиль тукталышлары, чүп савытлары) кору, теләсә нинди корылмаларны торгызу, шул исәптән ныклап төзелмәгән стационар булмаганнарын да, рөхсәт ителми, хезмәт күрсәтүгә катнашы булган һәм техник зонадан уза торган коммуникацияләрне эксплуатацияләү өчен техник корылмалардан тыш.

7.5.3. Су саклау зоналары территорияләрен төзекләндерүне су законнарына туры китереп проектларга кирәк.

## 8 БҮЛЕК.
## ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ОБЪЕКТЛАРЫН ЭКСПЛАТАЦИЯЛӘҮ

8.1. Территорияне җыештыру.

8.1.3. Үчәлле авыл җирлеге территориясендә җитештерү һәм куллану калдыкларын санкцияләнмәгән урыннарда тупларга һәм урнаштырырга тыела. Җитештерү һәм куллану калдыкларын сакцияләнмәгән урыннарда урнаштырган затлар әлеге территорияне үз хисабына җыештырырга һәм чистартырга, ә зарурлык булганда – җир кишәрлеген рекультивацияләргә тиеш.

Җитештерү һәм куллану калдыкларын санкцияләнмәгән чүплекләрдә урнаштырган затларны билгеләве мөмкин булмаган очракларда, җитештерү һәм куллану калдыкларын җыештыруны һәм чүплек территорияләрен рекультивацияләүне әлеге Кагыйдәләрнең 8.1.1 пункты нигезендә әлеге территорияне җыештыруны тәэмин итәргә бурычлы затлар хисабыннан башкарырга.

8.1.4. Җитештерү һәм куллану калдыкларын җыюны һәм чыгаруны контейнерлы яки савытсыз система буенча гамәлгә ашырырга.

8.1.5. Үчәлле авыл җирлегенең уртак файдаланудагы территориясендә җитештерү һәм куллану калдыкларын яндыруны тыярга.

8.1.6. Авыл җирлеге территориясен җыештыруны оештыруны калдыкларның аларны җитештерүчеләрдә калдыклар барлыкка килүнең норматив күләм күрсәткечләреннән файдалану нигезендә гамәлгә ашырырга.

8.1.7. Җитештерүдән һәм кулланудан калган көнкүреш калдыкларын торак йортлардан, сәүдә оешмаларыннан һәм җәмәгать туклануы, мәдәният, балалар һәм дәвалау биналарыннан чыгаруны аталган оешмаларга һәм йорт хуҗаларына, шулай ук алардан файдалану нәтиҗәсендә калдыклар барлыкка килгән чималның, материалларның, ярымфабрикатларның, башка төрле эшләнмәләрнең яки продуктларның, шулай ук товарларның (продукцияләрнең) бүтән милекчеләренә (алга таба – калдыклар җитештерүче) мөстәкыйль рәвештә яки махсус оешма белән шартнамәләр нигезендә башкарырга.

Ремонт вакытында барлыкка килгән калдыкларны чыгаруны моның өчен махсус билгеләнгән урыннарга әлеге ремонтны башкаручы затлар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырырга.

Ремонт вакытында барлыкка килгән калдыкларны калдыкларны вакытлыча саклау урыннарына урнаштыруны тыярга.

8.1.8. Әлеге Кагыйдәләрнең 8.1.1 пунктында күрсәтелгән физик һәм юридик затларның җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю өчен калдыкларны вакытлыча саклау урыннарын оештырырга һәм аларны җыештыруны һәм аларга техник хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашырырга.

Калдыкларны вакытлыча саклау урыннарын урнаштыруга рөхсәт, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге һәм Азнакай районында һәм Азнакай шәһәрендә Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Территориаль бүлеге белән килештерелгәннән соң, авыл җирлеге башлыгы тарафыннан бирелә.

8.1.9. Әгәр аларны куллану барышында калдыклар барлыкка килгән чималның, материалларның, ярымфабрикатларның, бүтән эшләнмәләрнең яки продуктларның, шулай ук товарларның (продукциянең) бүтән, үзенең көнкүреш һәм хуҗалык эшчәнлеген җир кишәрлегендә, торак яки торак булмаган бинада аренда шартнамәсе яки милекче белән төзелгән башка төрле килешү нигезендә гамәлгә ашыра тора торган милекчеләре (алга таба – калдыклар җитештерүче) калдыкларны җыюны, чыгаруны һәм утильләштерүне мөстәкыйль рәвештә оештырмаса, әлеге җитештерүче калдыкларын җыю, чыгару һәм утильләштерү бурычы югарыда аталган күчемсез мөлкәт объектларының әлеге Кагыйдәләрнең 8 нче бүлеге нигезендә территорияләрне җыештыру өчен җаваплы булган милекчесенә йөкләнә.

8.1.10. Урамнарның, мәйданнарның, скверларның һәм башка төрле иҗтимагый урыннарның җитештерү һәм куллану калдыклары белән чүпләнүен булдырмас өчен калдыкларны вакытлыча саклау өчен кече зурлыктагы савытлар (чүп савытлары, баклар) урнаштырыла.

Җитештерү һәм куллану калдыкларын вакытлыча саклау савытларын урнаштыруны һәм аларны чистартуны әлеге Кагыйдәләрнең 8.1.1 пункты нигезендә тиешле территорияләрне җыештыру өчен җаваплы затлар тарафыннан гамәлгә ашырырга.

Чүп савытларын (бакларны) төзек һәм пөхтә торышта карап тотарга, чүп тулу дәрәҗәсенә карап чистартырга һәм пычрану дәрәҗәсенә карап юарга.

8.1.11. Контейнер мәйданчыгыннан җитештерү һәм куллану калдыкларын, контейнерлардагы чүпне чүп ташу транспортына бушатканда коелган калдыкларны җыештыру калдыкларны чыгаручы оешма хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.1.12. Калдыклар чыгаруны аларны ташыганда югалту мөмкинлеген, аварияле хәл барлыкка килүне, транспорт белән күчерелә торган калдыклардан кешеләрнең сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян килүне булдырмаслык ысуллар белән гамәлгә ашырырга кирәк.

Куркынычлы калдыкларны чыгаруны Россия Федерациясе законнарындагы таләпләргә туры китереп, лицензиясе булган оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырырга кирәк.

8.1.13. Төнге вакытта җыештырганда тавыш кисәтә торган чаралар кулланырга.

8.1.14. Автобус тукталышларын җыештыру һәм чистарту әлеге тукталышлар урнашкан урам территорияләрен җыештыру йөкләмәсе бирелгән оешмалар тарафыннан башкарыла.

8.1.15. Автобусларның соңгы тукталыш урыннарын, диспетчер пунктлары территорияләрен җыештыру һәм чистарту әлеге объектларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан тәэмин ителә.

Ныклап төзелмәгән стационар булмаган сәүдә объектлары урнашкан тукталышларны җыештыру һәм чистарту, әгәр җир кишәрлегенең аренда, җир кишәрлегеннән түләүсез нигездә билгеле бер вакытка файдалану, гомер буенча мирас итеп алып, ия булу шартнамәләрендә башкасы билгеләнмәсә, чиктәш территорияләр чикләрендә ныклап төзелмәгән стационар булмаган объектларның хуҗалары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.1.16. Су алу колонкаларын эксплуатацияләү һәм тиешле санитар-техник торышта карап тоту, шул исәптән аларны чүптән, боздан һәм кардан чистарту, шулай ук аларга килә торган куркынычсыз юллар белән тәэмин итү әлеге колонкалар кем милкендә торса, шул оешмага йөкләнә.

8.1.17. Базарларның территорияләрен чистарту һәм җыештыру эшләрен оештыру гамәлдәге санитар нормалар һәм базарларда сәүдә итү нормалары нигезендә базарлар хакимиятләренә йөкләнә.

8.1.18. Скверларны һәм аларга чиктәш булып торучы тротуарларны, юлларны һәм газоннарны карап тоту һәм җыештыру авыл җирлеге хакимияте белән килешү нигезендә тиешле финанс елына бу максатлар өчен авыл җирлеге бюджетында каралган акча хисабына яшелләндерүче махсус оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.1.19. Оешмалар, биналарның милекчеләре мөлкәтендә яки янәшә территорияләрдә торучы бакчаларны, скверларны, паркларны, яшел утыртмаларны карап тоту һәм җыештыру әлеге оешмаларның, биналарның милекчеләренең көче һәм һәм алар хисабыннан мөстәкыйль рәвештә яки авыл җирлеге хакимияте контроле астында махсус оешмалар белән шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

8.1.20. Күперләрне, юлүткәргечләрне, җәяүле кичүләрен, аларга чиктәш булып торучы территорияләрне җыештыру әлеге объектларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.1.21. Канализациясе булмаган торак биналарда бәдрәф һәм юынтык нәҗесләрен җыю өчен үткәрми торган төпле, диварлар һәм чокырга зур предметлар эләгүеннән каршы рәшәткәле капкачлар белән җылытылган казылма чокырлар булдыруны күздә тотарга.

Юынтык суны тутыру, юынтык суны һәм нәҗесләрне бушату җайламаларын йортларның һәм урамнарның территорияләреннән читкә урнаштыруны, җитештерү һәм куллану калдыкларын урам юлларына чыгаруны тыярга.

8.1.22. Сыек нәҗесләрне шартнамәләр нигезендә яки махсус транспорты булган оешмаларга бер бирелә торган заявкалар буенча чыгарырга кирәк.

8.1.23. Биналарның милекчеләренә турыдан-туры чүп җыю урыннарына

һәм казылма чокырларга килү юлларын тәэмин итәргә.

8.1.24. Җир өслегендәге һәм грунт суларын ишегалларыннан чыгару өчен билгеләнгән су җыелып торучы канауларны, улакларны, трубаларны, дренажларны чистартуны һәм җыештыруны әлеге Кагыйдәләрнең 8.1.1 пунктында күрсәтелгән затларга гамәлгә ашырырга.

8.1.25. Тротуарларга, газоннарга, юлның хәрәкәт өлешенә су агызуга юл куелмаска тиеш, ә авария эшләрен уздырганда суны бары тик махсус агызу җайланмалары яки шланглар буйлап кына, коммуникацияләрнең хуҗалары белән килешү буенча һәм ташланган агынтыларны агызу эшләренә тотылган чыгымнарны түләп, якында урнашкан бәдрәф коеларына яки явым-төшем канализациясенә агызырга рөхсәт ителә.

8.1.26. Чүпне системалы рәвештә, туплану дәрәҗәсенә карап, ләкин өч көнгә бер мәртәбәдән артмаган ешлыкта, ә һава температурасы 5 градустан югары торган ел чорында көн саен чыгарырга киңәш ителә.

8.1.27. Җитештерү һәм куллану калдыкларын санкцияләнгән рәвештә саклау урыннарын карап тотуны һәм эксплуатацияләүне билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырырга.

8.1.28. Электртапшыру линияләрен, газ, сууткәрү һәм җылылык челтәрләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән территорияләрне җыештыру һәм чистарту күрсәтелгән челтәрләрне һәм электртапшыру линияләрен эксплуатацияләүче оешмаларның көче белән һәм алар хисабыннан гамәлгә ашырыла. Әгәр әлеге пунктта күрсәтелгән челтәрләр хуҗасыз булса, территорияләрне җыештыруны һәм чистартуны хуҗасыз мөлкәтне саклауны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү турында шартнамә төзелгән оешма гамәлгә ашыра.

8.1.30. Карау коеларын, җир асты грунт коммуникацияләрен чистартканда чүп-чарны, нәҗесләрне махсус савытка урнаштырып барырга, чистарту эшләре белән шөгыльләнүче оешмалар көче белән кичекмәстән чыгарырга.

Нәҗесләрне урамнарның юл өлешенә, тротуарларга һәм газоннарга урнаштырырга рөхсәт ителми.

8.1.31. Урамнарга ташланган, юл хәрәкәтенә комачаулык итә торган предметларны җыеп алу әлеге объектларны эксплуатацияләүче оешмаларга йөкләнә.

8.1.32. Үчәлле авыл җирлеге хакимияте ирекле нигездә авыл җирлеге территориясен җыештыру, төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләрен башкару өчен гражданнарны җәлеп итәргә мөмкин.

Гражданнарны авыл җирлеге территориясен җыештыру, төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләрен башкаруга җәлеп итү Үчәлле авыл җирлеге хакимияте карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

8.2. Язгы-җәйге чорда территорияне җыештыру үзенчәлекләре.

8.2.1. Язгы-җәйге чорда территорияне 1 апрельдән башлап 31 октябрьгә кадәр җыештырырга һәм урамнарның юл өлешен, тротуарларны, мәйданнарны себерүне күздә тотарга киңәш ителә.

8.3. Көзге-кышкы чорда территорияне җыештыру үзенчәлекләре.

8.3.1. Территорияне көзге-кышка чорда җыештыру чоры 1 ноябрьдән 31 мартка кадәр билгеләнә һәм чүп, кар һәм боз, пычрак җыештыруны һәм чыгаруны, урамнарга хлорид катнашмалы ком сибеп чыгуны күздә тота.

8.3.2. Хлорид кушылган ком белән сибеп чыгуны кар ява башлау яки бозлавык барлыкка килү белән кичекмәстән башларга кирәк. Бозлавык булганда иң беренче чиратта басмаларга, югарыга күтәрелә торган урыннарга, юллар киселешкән урыннарга, җәмәгать транспорты тукталышларына, җәяүле кичүләренә сибелә.

Тротуарларга хлоридсыз коры ком сибеп чыгарга.

8.3.3. Түбәләрне кардан чистартуны һәм боз сөңгеләреннән арындыруны түбәндәге куркынычсызлык чараларын тәэмин итеп башкарырга: кизү торучыларны билгеләү, тротуарларны коймалап алу, биек урында эшләүче затларны саклагыч җайланмалар белән тәэмин итү.

8.3.4. Асфальт түшәмәле барлык тротуарларны, ишегалларын, урамнарның юл өлешендәге улакларны, мәйданнарны, яр буйларын, базар мәйданчыкларын һәм башка урыннарны кардан һәм бозланган өслектән кырып чистартырга һәм иртәнге 8 сәгатькә кадәр ком сибәргә.

8.3.5. Урамнардан, мәйданнардан, күперләрдән, плотиналардан, скверлардан һәм бульварлардан боз һәм кар, кар ява башлау белән, кичекмәстән җыештырыла һәм чыгарыла башлый һәм, иң беренче чиратта, бозлы-карлы түшәлмә барлыкка килүне булдырмас өчен транспортларның өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү максатында үзәк урамнардан, автобус трассаларыннан, күперләрдән, плотиналардан һәм юлүткәргечләрдән башкарыла.

8.3.6. Урамнарны, юлларны, мәйданнарны махсус оешмалар тарафыннан җыештырганда әлеге Кагыйдәләрнең 8.1.1 пунктында күрсәтелгән затларга кар чистарту техникасы узып киткәннән соң бордюрлар янәшәсендәге улакларны җыештыруны һәм керә торган юлларны, җәяүле кичүләрен юлның төзелмәләр булган ягыннан да, әгәр анда башка төзелмәләр булмаса, кара-каршы ягыннан да чистартуны тәэмин итәргә.

8.4. Төзекләндерү элементларын карап тоту тәртибе.

8.4.1. Төзекләндерү элементларын карап тотуга карата гомуми таләпләр.

8.4.1.2. Коймаларны, киртәләрне, газон һәм тротуар коймаларын, киоскларны, палаткаларны, павильоннарны, ларекларны, игълан такталарын һәм башка җайланмаларны төзү һәм урнаштыру Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында, Үчәлле авыл җирлеге Советы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

8.4.1.3. Төзелеш мәйданчыкларын барча периметры буйлап билгеләнгән үрнәктәге тыгыз койма белән киртәләп алырга кирәк. Коймалар аша үтеп керү юлларының минималь күләмен күздә тотарга кирәк. Коймалар аша үтү юллары ярдәмче юлларга чыгарга һәм шлагбаумнар яки капкалар белән җиһазландырылырга тиеш.

Төзелеш мәйданчыкларын тәгәрмәчләрне чистарту җайланмасы белән һәр койма аша үтү юлында кимендә 20 метрлы төзекләндерелгән юл өлеше белән

тәэмин итәргә кирәк.

8.4.2. Утлы алтакталар, реклама һәм витриналар.

8.4.2.1. Теләсә нинди төрдәге алтакталарны урнаштыру фәкать эскизларын Үчәлле авыл җирлеге хакимияте белән килештергәннән соң гына рөхсәт ителә.

8.4.2.3. Витриналар махсус яктырту җайланмалары белән җиһазландырылган булырга тиеш.

8.4.2.4. Газеталарны, афишаларны, плакатларны, төрле төрдәге игъланнарны һәм рекламаларны махсус билгеләнгән стендларда гына ябыштырырга рөхсәт ителә.

8.4.2.5. Электр транспорты, урам яктырту баганаларын, биналарның цокольләрен, коймаларны һәм башка корылмаларны игъланнардан чистарту әлеге объектларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.4.2.6. Тышкы реклама чараларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү Азнакай районы Советы карарында билгеләнгән тәртиптә рөхсәт ителә.

8.4.3. Кече архитектура формаларын төзү, урнаштыру һәм карап тоту.

8.4.4. Биналарны һәм корылмаларны төзәтү һәм карап тоту.

8.4.4.1. Биналарны һәм корылмаларны эксплуатацияләүне, аларны төзәтүне Техник эксплуатация кагыйдәләрендә һәм нормаларында билгеләнгән тәртиптә башкарырга.

8.4.4.2. Биналарга һәм корылмаларга агымдагы һәм капиталь ремонтны, фасадларны буяны аларның техник торышына карап, биналарның һәм корылмаларның милекчеләре тарафыннан яки милекче белән бүтән зат арасында төзелгән килешү нигезендә башкарырга.

8.4.4.3. Биналарның фасадларын аларның аерым детальләрен юкка чыгаруга яки үзгәртүгә бәйле рәвештә төрлечә үзгәртүләрне, шулай ук яңа тәрәзә һәм төп фасадка керә торган ишек уемнарын урнаштыруны һәм булганнарын реконструкцияләүне авыл җирлеге хакимияте белән килештерү нигезендә башкарырга.

8.4.4.4. Үчәлле авыл җирлеге хакимиятеннән тиешле рөхсәтне алмыйча хуҗалык һәм ярдәмче корылмаларны (агач сарайларны, будкаларны, гаражларны, күгәрчен асрау урыннарын, теплицаларны һ.б.) үзирекле торгызып кую тыела.

8.4.4.5. Балконнарга, лоджияләргә нинди дә булса үзгәрешләр кертергә, келәмнәрне, киемнәрне, урын-җирләрне биналарның урам ягына карап торучы тышкы фасадларындагы балконнарына һәм тәрәзәләренә эләргә, аларны йортта кулланыла торган төрле предметлар белән капларга рөхсәт ителми.

8.4.4.6. Ишегалды территорияләрен металл ломы, төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, йорт кирәк-яраклары һәм башка материаллар белән капларга һәм чүпләргә рөхсәт ителми.

8.4.4.7. Урам аталышын һәм йортның номер тамгаларын, ә почмак йортларга кисешкән урамнарның аталышларын күрсәтеп, билгеләнгән үрнәктәге күрсәткечләрне биналарга урнаштырып чыгарга.

8.5. Территорияләрне яшелләндерү һәм яшел утыртмаларны карап тоту

эшләре.

8.6.1. Территорияне яшелләндерү, паркларны, скверларны, яшел зоналарны карап тоту һәм торгызу, муниципаль урманнарны карап тоту һәм саклау эшләрен бу максатларга авыл җирлеге бюджетында каралган чаралар хисабыннан авыл җирлеге белән шартнамәләр нигезендә махсус оешмалар гамәлгә ашыра.

8.6.3. Урамнарның, мәйданнарның, паркларның, скверларның территорияләренә яңа агачлар утырту, скверларны һәм паркларны чәчәкләр белән бизәү, шулай ук ландшафт архитектурасы объектларын капиталь ремонтлау һәм конструкцияләү эшләрен фәкать авыл җирлеге хакимияте белән килештерелгән проектлар буенча гына башкарырга.

8.6.6. Агачларны һәм куакларны үзирекле рәвештә кисү тыела.

8.6.7. Авыл җирлеге җирләрендә үсә торган, авыл җирлегенең йортлар салу яки җир асты коммуникацияләрен салу, югары вольтлы линияләр һәм башка төрле корылмалар урнаштыру зоналарына эләгә торган зур агачларны һәм куаклыкларны фәкать авыл җирлеге хакимиятенең язмача рөхсәте нигезендә генә алып атырга.

8.6.8. Авыл җирлеге җирләрендә үсә торган, авыл җирлеге җирләрендә урнашкан зур агачларны һәм куаклыкларны йортлар салуга яки җир асты коммуникацияләрен салуга бәйле рәвештә алып аткан өчен торгызу бәясе алына. Яшел утыртмаларны торгызу бәясенең күләме Үчәлле авыл җирлеге хакимияте тарафыннан әйләнә-тирәлекнең бозылган торышын торгызуга фактта тотылган чыгымнарга карап, китерелгән югалтуларны исәпкә алып, шул исәптән торгызу эшләренең проектларына туры китереп билгеләнә. Яшел утартмаларны торгызу бәясе Үчәлле авыл җирлеге бюджетына күчерелә.

8.6.9. Агачларны һәм куакларны алып атуга рөхсәт бирүне торгызу бәясе түләнгәннән соң гамәлгә ашырырга кирәк. Әгәр аталган утыртмалар күчереп утыртылырга тиешле булса, рөхсәтне торгызу бәясен түләтмичә бирергә кирәк. Авыл җирлеге территориясендә агачлар һәм куаклар утырту урыннары авыл җирлеге хакимияте тарафыннан билгеләнә.

8.6.10. Яшел утыртмаларны төрлечә зарарлаган яисә үзирекле рәвештә кискән өчен, шулай ук яшел утыртмаларга карата саклык чараларын күрмәгән һәм битараф мөнәсәбәттә булган өчен гаепле затлардан зыян салынган яки һәлак ителгән утыртмаларның торгызу бәясе түләттерелә.

8.6.11. Җиләк-җимеш бирүче утыртмаларның һәм гражданнарныкы булган һәм торак һәм сәнәгый биналарны төзү зоналарына эләгә торган бакчаларның хакын билгеләү Үчәлле авыл җирлеге хакимияте тарафыннан башкарыла.

8.6.12. Муниципаль урманнар территориясендә агачларны законсыз кискән яки зарарлаган өчен гаепле затлар китерелгән зыянны түли.

8.6.13. Агачларны һәм куакларны исәпкә алу, аларны карап тоту, аларга ярлык тагу, аларны алып ату, кискәләү, күчереп утырту пассажир транспорты маршрутлары уза торган урамнарда махсус оешмалар тарафыннан башкарыла; күпкатлы тораклар салынган территорияләрдә ишегаллары эчендә – торак-

эксплуатация оешмалары тарафыннан; муниципаль урманнарда – урман хуҗалыгы яки башка төрле махсус оешма тарафыннан.

Әгәр бу вакытта агачларның аерым гражданнар гаебе белән һәлак булуы билгеле булса, ул чакта торгызу бәясенең күләме агач сәламәтлегенә булган бәяләр нигезендә билгеләнә.

8.6.14. Агачларга зыян салыну билгеләре ачыкланганда яшел утыртмаларны саклау өчен җаваплы булган затларга кирәкле чараларны күрү өчен кичекмәстән Үчәлле авыл җирлеге хакимиятенә хәбәр итәргә кирәк.

8.6.15. Корыган агачларны кисүгә рөхсәт Үчәлле авыл җирлеге хакимияте тарафыннан бирелә.

8.6.16. Агачларның кыйммәтле токымнарыннан тыш, хосусый төзелеш зонасында агачларны һәм куакларны алып ату җир кишәрлекләре милекчеләре тарафыннан үз хисабына гамәлгә ашырыла.

8.6. Юлларны карап тоту һәм эксплуатацияләү.

8.7.1. Үчәлле авыл җирлеге территориясендә юл түшәмәләрен саклау максатында түбәндәгеләрне тыярга:

- йөкне транспорт белән сөйрәтеп китерүне;

- төяү-бушату эшләрен башкарганда урамнарга рельслар, бүрәнәләр, тимер балкалар, трубалар, кирпечләр, башка төрле авыр предметлар ташлауны һәм аларны өеп куюны;

- каты түшәмәсе булган торак пунктлары урамнары буйлап чылбырлы машиналарны йөртүне.

8.7.2. Махсус оешмаларга әлеге Кагыйдәләрнең 8.2.1 пунктында аталган затлар белән килешүләр нигезендә Үчәлле авыл җирлеге территорияләрен җыштырып торырга.

8.7.3. Авыл җирлеге чикләрендә уртак файдаланудагы автомобиль юлларын, күперләрне, тротуарларны һәм бүтән транспорт инженер корылмаларын (федераль һәм региональ билгеләнештәге уртак файдаланудагы автомобиль юлларыннан, күперләрдән һәм башка транспорт инженер корылмаларыннан тыш) агымдагы һәм капиталь ремонтлау, карап тоту, төзү һәм реконструкцияләү махсус оешмалар тарафыннан капитал кертүләр планы нигезендә авыл җирлеге хакимияте белән шартнамәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

8.7.4. Юл билгеләрен, тамгаларны һәм иминлекле урам-юл хәрәкәтен тәэмин итү объектларын эксплуатацияләү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау авыл җирлеге хакимияте белән шартнамәләр нигезендә махсус оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.7.5. Оешмаларга үз карамагындагы юл челтәрләре коммуникацияләренең люклары һәрвакыт юл өслеге дәрәҗәсендә, даими рәвештә төзек һәм ябык торышта булуын күзәтеп торырга.

Урамнарның юл өлешендә һәм тротуарларда урнашкан люкларның, коеларның капкачларын, әгәр аларга зыян килсә яки җимерелсә, кичекмәстән коймалап алырга һәм 6 сәгать эчендә әлеге коммуникацияләр кем карамагында торса, шул оешмалар тарафыннан торгызырга кирәк.

8.7. Территорияне яктырту.

8.8.1. Урамнарны, юлларны, мәйданнарны, күперләрне, бульварларны һәм җәяүле аллеяларын, иҗтимагый һәм рекреация территорияләрен, торак кварталларының, торак йортларның территорияләрен, сәнәгый һәм коммуналь оешмаларның территорияләрен, шулай ук юл тамгаларын һәм күрсәткечләрне, торак пунктлары турындагы мәгълүмат элементларын авыл җирлеге хакимияте тарафыннан расланган расписание буенча тәүлекнең караңгы вакытында яктыртырга кирәк.

Уртак файдаланудагы урыннарны яктырту вазыйфасы җирле үзидарә органнарына йөкләнә, башка объектларны яктырту вазыйфасы аларның милекчеләренә яки милекче вәкаләт биргән затларга йөкләнә.

8.8.2. Авыл җирлеге территориясен яктырту билгеләнгән тәртиптә үзләренә бүленгән җир кишәрлекләренең милекчеләре булып торган физик һәм оешу-хокукый формасына бәйсез рәвештә юридик затлар белән шартнамәләр нигезендә энергия белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.8.3. Урамнарны тышкы яктан яктырту челтәрләрен төзү, эксплуатацияләү, агымдагы һәм капиталь төзекләндерү авыл җирлеге хакимияте белән шартнамәләр нигезендә махсус оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.8. Коммуникацияләрне төзегәндә, ремонтлаганда, реконструкцияләгәндә эшләр уздыру.

8.9.1. Грунтны яки юл түшәмәләрен казып ачуга бәйле эшләрне (җир асты коммуникацияләрен салу, реконструкцияләү яки төзәтү, субайлар һәм ырмау сугу, грунтны планлаштыру, бораулау эшләре) фәкать район хакимиятеннән бирелгән язмача рөхсәт (җир эшләрен уздыруга ордер) булганда гына башкарырга. Челтәрләрнең хуҗалары авария эшләрен, алга таба 3 көнлек срокта рөхсәт рәсмиләштереп, авыл җирлеге хакимиятенә телефонограмма җибәреп яки хәбәр итеп башлыйлар.

8.9.2. Коммуникацияләрне төзү, реконструкцияләү, төзәтү буенча эшләр башкаруга рөхсәтне район хакимияте бирә, түбәндәгеләрне күрсәткәндә:

– мәнфәгатьле хезмәтләр белән килештерелгән, инженер коммуникацияләренең сакланышы өчен җавап бирә торган эшләрне уздыру проектын;

– юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча дәүләт инспекциясе белән килештерелгән транспорт һәм җәяүле хәрәкәте схемасын;

– авыл җирлеге хакимияте белән килештерелгән эшләрне башкару шартларын;

– эшләр башкаруның календарь графигын, шулай ук коммуникацияләрне төзү, реконструкцияләү, төзәтү буенча эшләр аның башкарылачак территориясенең милекчесе яки аның тарафтан вәкаләт бирелгән зат белән җир кишәрлеген төзекләндерү турында килешүне.

Юлларның, тротуарларның яки газоннарның өслеген торгызу зарурлыгы белән бәйле эшләрне башкарганда җир эшләрен башкаруга рөхсәт бары тик юл өслегенә, тротуарларга, газоннарга хезмәт күрсәтүче махсус оешма

белән килештерү нигезендә генә бирелә.

8.9.3. Кысынкы шартларда җир асты коммуникацияләрен салу зарурлыгы булганда күчмә коллекторлар коруны күздә тотарга кирәк. Коллекторларны проектлауны челтәрләрнең үсеш перспективасын исәпкә алып гамәлгә ашырырга.

8.9.4. Урамнарның юл өлеше, транспорт үтү юллары, шулай ук тротуарлар астында җир асты коммуникацияләрен салу, траншея киңлегенә бәйсез рәвештә, автоюлның (тротуарның) тулы киңлеген торгызу шарты белән, тиешле оешмалар тарафыннан рөхәт ителә.

Юл астында урнашкан конструкцияләрдә, җир асты коммуникацияләрендә кирпеч куллануга юл куймаска.

8.9.5. Яңа төзелгән (реконструкцияләнгән) урамнарны, скверларны яңадан казу мөмкинлеген булдырмау максатларында киләсе елда җир асты челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү буенча эшләрне гамәлгә ашырырга тиешле оешмалар төзелеш елы алдыннан килгән елның 1 ноябренә кадәрле срокта авыл җирлеге хакимиятенә эшләр башкаруның күздә тотылган срокларын күрсәтеп, коммуникацияләр салу буенча ниятләнгән эшләр турында хәбәр итәргә тиеш.

8.9.6. Җир асты коммуникацияләрен салганда яки башка төрле төзелеш эшләрен башкарганда төзелеш һәм ремонт оешмалары гаебе белән юл өслекләренә, яшелләндерү һәм төзекләндерү элементларына китерелгән барлык зыяннарны һәм җимереклекләрне эшләр башкаруга рөхсәт алган оешмаларга авыл җирлеге хакимияте белән килештерелгән срокларда тулы күләмендә бетерергә кирәк.

8.9.7. Казу буенча эшләрне башлап җибәргәнчегә кадәр түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

8.9.7.1. Килешенгән схемага туры китереп, юл билгеләрен урнаштырырга;

8.9.7.2. Эшләр башкарылачак урынны киртәләп алырга, коймаларга эшләрне башкаручы оешманың аталышы, эшләрне башкару өчен җаваплы затның фамилиясе, оешманың телефон номеры белән табличка элеп куярга.

Койманы пөхтә торышта тотарга, юлга якын җирдә эшләр башкарганда машина йөртүчеләр һәм җәяүлеләр өчен күренеп торуны тәэмин итәргә, тәүлекнең караңгы вакытында кызыл сигнал фонарьлары белән билгеләргә кирәк.

Киртәләп алуны тоташ һәм ышанычлы, чит-ятларның төзелеш мәйданына үтеп керүен чикләрлек итеп башкарырга кирәк.

Траншеялар аша массакүләм җәяүлеләр агымы юнәлешләрендә бер-берсеннән кимендә 200 метр ераклыкта күперләр урнаштырырга кирәк.

8.9.7.3. Эшләрне башкару пассажир транспорты маршрутларын ябу, үзгәртү белән бәйле булган очракларда эшләрнең срокларын күрсәтеп, матбугатта тиешле игъланнар урнаштырырга.

8.9.7.4. Зарурлык булганда билгеләнгән тәртиптә яшел утыртмаларны кисүне яки күчереп утыртуны рәсмиләштерергә һәм гамәлгә ашырырга. Җир

асты коммуникацияләрен төзәткәндә яки реконструкцияләгәндә коммуникацияләрне салганнан соң утыртылган яшел утыртмаларны аларга кадәр рөхсәт ителгән аралыктан кимрәк ераклыкка күчерү зарурлыгы барлыкка килгән очракта, әлеге утыртмаларның баланс бәясе алынмый.

8.9.8. Эшләр башкаруга рөхсәт эшләр барган урында саклана һәм эксплуатация нормалары үтәлешен тикшереп торучы затларның беренче таләбе буенча чыгарып күрсәтелә.

8.9.9. Рөхсәттә эшләр башкаруның сроклары һәм шартлары билгеләнгән булырга тиеш.

8.9.10. Җир эшләрен башлап җибәрер алдыннан төзелеш оешмасына әлеге урынга эксплуатация хезмәтләрен чакыртырга кирәк, алар үз коммуникацияләренең урындагы торышын тәгаенләштерергә һәм эшләр башкаруның махсус шартларын язмача формада теркәргә бурычлы. Махсус шартлар җир эшләрен башкаручы төзелеш оешмасы тарафыннан тайпылышсыз үтәлергә тиеш.

8.9.11. Вәкил килмәгән очракта яки коммуникацияләрнең төгәл урнашкан урынын күрсәтүдән баш тартканда, тиешле акт төзелә. Бу вакытта эшләрне башкаручы оешма коммуникацияләрнең топографик нигездә күрсәтелгән нигезләмәсенә таянып эш итә.

8.9.12. Урамнарның юл өлешендә эшләр башкарганда траншея чикләрендәге асфальт һәм вак таш эшләрне башкаручы тарафыннан сүтелә һәм махсус билгеләнгән урынга чыгарыла.

Бордюр сүтелә, алга таба яңадан урнаштыру өчен эшләр башкарылган урында өеп куела.

Урамнарда, йортлар салынган территорияләрдә эшләр башкарганда грунт кичекмәстән чыгарыла.

Зарурлык булганда төзелеш оешмасы грунтны читкә өеп куюны планлаштыра.

8.9.13. Юл һәм тротуарлар астындагы траншеялар катлы-катлы нығытып һәм су сибеп, ком һәм комлы фунт белән күмелә. Газоннардагы траншеяларны уңдырышлы өслеген торгызып һәм үлән чәчеп нығытып, җирле грунт белән күмәргә.

8.9.14. Геодезик сурәте ясалганчыга кадәр траншеяны күмәргә рөхсәт ителми. Җир эшләрен башкаруга рөхсәт алган оешма эшләрне тәмамлаганчыга кадәр геодезик сурәтен башкара.

8.9.15. Төзекләндерелмәгән территорияләрдә эшләр башкарганда алга таба күмү өчен казылган грунтны бер яктан өеп куярга рөхсәт ителә.

8.9.16. Траншеяны кирәкле тыгызлаудан башка гына кондицияләнмәгән грунт белән күмгәндә яки Җир эшләрен башкару кагыйдәләрен башкача бозганда, авыл җирлеге хакимиятенең вәкаләтле затлары гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту өчен беркетмә төзү хокукына ия була.

8.9.17. Җир өсте коммуникацияләре өстендә дә, төзәтү-торгызу эшләре алып барылмаган башка урыннарда да, ләкин алар нәтиҗәсендә төзәтү-торгызу эшләрен уздырганнан соң 2 ел эчендә барлыкка килгән убылулар, грунт яки юл

өслеге иңгән урыннар эшләр башкаруга рөхсәт алган оешма тарафыннан тәүлек эчендә тәртипкә китерелә.

Җир асты коммуникацияләрендә аварияләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән боз катламнарын оешмалар – коммуникацияләрнең хуҗалары яки коммуникацияләрнең хуҗалары хисабыннан махсус оешмалар шартнамә нигезендә бетерә.

8.9.18. Коммуникацияләрне төзегәндә, төзәткәндә, реконструкцияләгәндә вакыты узган ордерлар нигезендә эшләр башкару җир эшләрен үзирекле рәвештә башкару булып таныла.

8.9. Хайваннар асрау.

8.10.1. Хайваннарның һәм кошларның хуҗалары үзләренең хайваннарының тискәре йогынтысын башка хайваннарга һәм кешеләргә булдырмаска, шулай ук санитар нормалар нигезендә әйләнә-тирәдәгеләр өчен тынычлык тәэмин итәргә, гамәлдәге санитария-гигиена һәм ветеринария нормаларын сакларга бурычлы.

Йорт хайваннарын асрау урыннары йорт хайваннарының хосусый, шул исәптән киңлеккә, температурага, яктылыкка, җилләтүгә бәйле, ихтыяҗларын исәпкә алып корылырга тиеш.

8.10.2. Йорт хайванын җир кишәрлегендә асраганда аның өчен аны асрау өчен яраклаштырылган, әлеге Кагыйдәләрнең 8.10.1 пунктындагы икенче абзацта билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган урын корылырга тиеш.

8.10.3. Авыл хуҗалыгы терлекләрен затлар озатуыннан башка авыл җирлеге территориясе буйлап йөртү тыела.

8.10.4. Авыл хуҗалыгы терлекләрен көтүне авыл җирлеге хакимияте тарафыннан махсус терлек көтү өчен билгеләнгән урыннарда хуҗасы яки аның тарафтан вәкаләт бирелгән зат күзәтүе астында гамәлгә ашырырга.

8.10.5. Токымнарына һәм билгеләнешенә (шул исәптән номер тамгасы сугылган муенчагы булган) бәйсез рәвештә, урамнарда яки бүтән җәмәгать урыннарында озата йөрүче заты булмаган этләрне һәм мәчеләрне тотарга.

8.10.6. Сәяйәр хайваннарны тоту авыл җирлеге хакимияте белән төзелгән шартнамәләр нигезендә әлеге максатларга авыл җирлеге бюджетында каралган чаралар чикләрендә махсус оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.10.7. Йорт хайванын торак урында асраганда аның хуҗасы әлеге торак урында яшәүче гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, санитар-эпидемиологик һәм ветеринария кагыйдәләрен, шулай ук торак урыннардан файдалану кагыйдәләрен үтәргә бурычлы.

8.10.8. Берничә гаилә яши торган торак урында йорт хайваны асрау бары тик аталган гаиләләрнең балигъләк яшенә җиткән барлык әгъзаларының язмача ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Күпфатирлы йортта торак урында потенциаль куркыныч токымлы эт асрау өчен шулай ук потенциаль куркыныч токым этен асрау планлаштырыла торган торак урын белән бер подъездда урнашкан торак урыннарында яшәүче балигъләк яшенә җиткән күпчелек гражданнарның язмача ризалыгын алу таләп ителә. Әлеге өлештә күрсәтелгән

таләпләр торак урыннарда (сукырларны) җитәкләп йөртүче этләрне асрау очракларына кагылмый.

8.10.9. Җир кишәрлегендә асрала торган эт бәйдә яки әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркынычсызлык тәэмин итү мөмкинлеген бирә торган вольерда тотылырга тиеш. Әгәр җир кишәрлеге этнең аннан мөстәкыйль рәвештә читкә чыгу мөмкинлеген калдырмаслык итеп киртәләп алынган булса, этне җир кишәрлегендә баусыз һәм вольердан читтә асрарга рөхсәт ителә. Җир кишәрлеге территориясенә кергәндә җир кишәрлегендә эт булуы турында кисәтү язуы урнаштырылырга тиеш.

8.10.10. 8.10.8 пункт таләпләре күпфатирлы йортларның торак урыннарында «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын асрауның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 07 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә 2015 елның 01 гыйнварына кадәр теркәлгән этләрне асрау очракларына кагылмый.

8.11. Авыл тирәлегеннән файдалану мөмкинлекләренә карата махсус таләпләр.

8.11.1. Торак тирәлеген, урамнарны һәм юлларны төзекләндерү объектларын, мәдәни-көнкүреш хезмәтләре күрсәтүче объектларны проектлаганда торак пунктларының тирәлегеннән өлкән яшьтәге затлар һәм инвалидлар файдалана алу мөмкинлеген күздә тотарга, әлеге объектларны картларга һәм инвалидларга хәрәкәт итүдә булыша торган элементлар һәм техник чаралар белән җиһазларга кирәк.

8.11.2. Өлкән кешеләргә һәм инвалидларга хәрәкәт итү өчен булыша торган техник чараларны һәм җайланмаларны проектлау, төзү, урнаштыру расланган проект документациясе нигезендә заказчы тарафыннан яңа төзелеш барышында гамәлгә ашырыла.

8.11. Территорияне бәйрәмчә бизәү.

8.12.1. Авыл җирлеге территориясен бәйрәмчә бизәү авыл җирлеге хакимияте карары нигезендә дәүләт һәм авыл бәйрәмнәрен, тантаналы вакыйгаларга бәйле чараларны уздыру чорында башкарыла. Биналарны, корылмаларны авыл җирлеге территориясен бәйрәмчә бизәү концепциясе кысаларында аларның хуҗалары тарафыннан бизәргә киңәш ителә.

8.12.2. Авыл бәйрәмнәрен һәм бәйрәм чараларын уздыруга бәйле эшләрне оешмалар тарафыннан үз хисабына мөстәкыйль, шулай ук авыл җирлеге хакимияте белән төзелгән шартнамәләр нигезендә әлеге максатларга авыл җирлеге бюджетында каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырырга киңәш ителә.

8.12.3. Бәйрәмчә бизәүгә түбәндәгеләрне кертергә киңәш ителә: милли флаглар, шигарьләр, гирляндалар, панно элү, декоратив элементлар һәм композицияләр, стендлар, киосклар, мөнбәрләр, эстрадалар урнаштыру, шулай ук бәйрәм иллюминациясен ясау.

8.12.4. Бәйрәмчә бизәү концепциясе чараның программасы һәм бәйрәмчә бизәү объектларын һәм элементларын урнаштыру схемасы белән

билгеләнә, алар авыл җирлеге хакимияте тарафыннан раслана.

8.12.5. Бәйрәмчә бизәү элементларын әзерләгәндә һәм урнаштырганда юл хәрәкәтен җайга салуның техник чараларын салдыру, аларга зыян китерү һәм аларның күренүен начарлату тыела.

## 9 БҮЛЕК.
## ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮДӘ ТОТУ

9.1. Әлеге Кагыйдәләрнең 8.2.1 пункты нигезендә затларга территорияне төзекләндерүне гамәлгә ашыр өчен җаваплы затларны билгеләргә киңәш ителә.

Үчәлле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү

**Төп терминнар һәм билгеләмәләр**

*Ассимиляцияле потенциал (сыем)* – экосистеманың үзлектән чистарыну сәләте, бер берәмлек вакыт эчендә тупланырга, җимерелергә һәм аның нормаль эшчәнлегенә зыян салмыйча экосистемадан читкә чыгарылырга мөмкин булган пычратучы матдәләр күләмен максималь сыйдыру күрсәткече.

*Бордюрлы пандус* – җәяүле юлыннан тәбәнәкләндерелгән яки батырылган бордюр ташы аша юл өслегенә чыгуны тәэмин итүче корылма.

*Вертикаль яшелләндерү* – балконнарны, лоджияләрне, галереяларны, терәүле диварларны һ.б. да кертеп, биналарның һәм корылмаларның фасад өслекләрен аларга стационар һәм мобиль яшел утыртмалар урнаштыру өчен куллану.

*Зоналарга бүленгәнлек (типик зонага бүленеш)* – территориянең табигый-географик шартларына карап, үсемлекләр структурасының сыйфатламалары.

*Түбә яшелләндерү* – биналарның һәм корылмаларның түбәләрен аларда архитектура-ландшафт объектлары (газоннар, чәчәклекләр, бакчалар, агачлар һәм куаклар белән мәйданчыклар һ.б.) ясау өчен файдалану.

*Ландшафт сәнгате объектларының күләмле-тирәлекле структурасы* – торак пунктындагы тирәлекне ландшафтлы оештыру методы яки формасы; күләмле-тирәлекле структура типлары: ябык (агачлыклар, биләмәләр, каенлыклар), ябык (аланнар, чирәмлекләр, партерлар, зур чәчәклекләр, мәйданчыклар, сулыклар, яссы спорт корылмалары), ярымачык (агачлыклар, төркемнәр, шулай ук ябык һәм ачык структура элементларының бергә килүе).

*Җәяүле зоналары* – торак пунктында халыкның җәяүләп йөреп керү һәм мәдәни-көнкүреш максатларында, транзит хәрәкәт итү максатларында хәрәкәт итүе гамәлгә ашырыла торган һәм билгеле бер сыйфатламаларга ия булган: урамныкы булмаган тизлекле һәм җир өсте җәмәгать транспорты тукталышлары булган, хезмәт күрсәтүче объектлар, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр, рекреацияләр һ.б. күпләп тупланган, җәяүле агымнарының суммар тыгызлыгы югары торган территория өлешләре. Җәяүле зоналары ачык урыннарда, җәяүле урамнарында, торак пунктындагы мәйданнарда җәяүлеләр йөри торган өлешләрдә формалашырга мөмкин.

*Җәяүле урамнары* – ул, кагыйдә буларак, торак пунктындагы төрле территорияләр һәм районнар арасында борын-борыннан барлыкка килгән, транспорт хәрәкәте өчен ябык һәм җәяүлеләр хәрәкәте өчен яраклаштырылган юллар. Җәяүле урамнарының оптималь озынлыгын 800-1200 м дәрәҗәсендә, киңлеген, объектларны ике яклап кабул итүдән чыгып, кимендә 10 м һәм 30 м артмаган дәрәҗәдә (оптималь – 12-20 м) билгеләргә киңәш ителә.

*Мәйданның җәяүлеләр өлеше* – мәйданның җәяүлеләр хәрәкәте өчен билгеләнгән урыннары һәм тирәлекләре, мәйданның барлык территориясендә дә (вәкиллекле һәм мемориал) яки аның бер өлешендә дә булырга мөмкин (объект каршында).

*Рекреацион потенциал* – территориянең билгеле бер сандагы ял итүчеләргә психофизиологик уңайлылык һәм табигать тирәлегеннән чикләнмичә ял итү (спорт-ныгыту эшчәнлеге) мөмкинлеген тәэмин итү мөмкинлеге. Мәйдан берәмлегенә кешеләр саны (яки кеше-көн) белән чагылдырыла.

*Утыртмаларның чыбылдык йомыклыгы* – утыртмалар чыбылдыгының яктылыксыз горизонталь (вертикаль) проекциясе мәйданының барлык чыбылдыкның горизонталь (вертикаль) проекциясе мәйданына нисбәте, берәмлекнең уннан бер өлешендә чагылдырыла.

*Тактиль түшәмә* – җир өслегендәге катлам фактурасын шактый үзгәртә торган түшәмә.

*Туфракның биологик пычрануы* – туфракның пычрану төре һәм дәрәҗәсе, бу вакытта ул үсемлеккә нормаль функцияләүне тәэмин итү мөмкинлеген югалта.

*Грунт* – табигый һәм антропоген барлыкка килгән минерал һәм органик матдәләрдән торучы субстрат.

*Минималь туфрак бүлемтеге* – агачка тулы яшәеш циклын тәэмин итәргә сәләтле өч үлчәнешле туфрак фрагменты.

*Уңдырышлы катлам* – табигый туфракларда ул черемә горизонты. Урбоконструктоземнарда – 20 см калынлыгында уңдырышлы грунттан торучы катлам (горизонт).

*Уңдырышлы грунт* – минерал һәм органик материалдан ясалма формалаша торган һәм бирелгән физик, химик һәм биологик үзлекләренә ия булган яки табигый черемә горизонтларыннан бозылган субстраттан торучы грунт. Уңдырышлы грунтта көнкүреш һәм төзелеш калдыклары булырга тиеш түгел. Физик балчык кушылдыгы (фракцияләр $<$ 0,01 мм) – кимендә 30-40%, черемә кушылдыгы - 3-4%, pH - 5,5-7,0.

*Туфрак хасил итүче грунт* – туфрак хасил итүче процессларда үзгәрә торган һәм үсемлекләргә оптималь яшәеш шартларын тәэмин итү үзлекләренә ия булган грунт.

